• НӘСЫЙХӘТ •
БӘХЕТЛЕ ҺӘМ НЫКЛЫ ГАИЛӘ СЕРЕ: ИР БЕЛӘН ХАТЫНГА 12 КИҢӘШ
5 бит

• ВӘГАЗЬ •
АЛЛАҺЫГА ШӨКЕР КЫЛЫП, РӘХМӘТЛЕ БУЛЫП ЯШӘҮ
6 бит

• КОРБАН •
КОРБАН ЧАЛУ АЛЛАҺЫГА ЯКЫНАЙТА
10 бит

• ҮРНӘК ЗАТЛАР •
ИМАМ МӘЛИК РАХИМӘҺУЛЛАҺИ
12 бит

№ 7 (288) *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *Зөлкагъдә 1440*

*Июль, 2019*

دين ومعيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Болгарда VIII Мөселман яшьләре форумы узды



«Болгар шәһәрендә сигезенче мөселман яшьләре форумы гөрләп узды. Быел ул 12-19 июль көннәрендә үткәрелде. Аллаһы рәхмәте белән миңа да бу чарада катнашырга насыйп булды».

*Болгардагы куңелле хатирәләре белән Айгөл Минһаҗева уртаклаша.*

*Дәвамы 8 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Мөфти Казанда урнашкан 18 нче төзәтү колониясендә булды



17 июль көнне Камил хәзрәт Сәмигуллин Казан шәһәрендә урнашкан 18 нче төзәтү колониясендәге тоткыннар белән очрашты. Очрашуда шулай ук республика мөселманнары башлыгының социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе Илдар хәзрәт Баязитов, «Ярдәм» Ислам милли хәйрия фонды президенты Илһам Исмәгыйлев, колония җитәкчелеге катнашты.

Әлеге колония Татарстанда иң кечкенәләрдән санала. Биредә тоткыннарның дини-рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен барлык шартлар тудырылган. Алар төзәтү учреждениесе территориясендәге “Нур” гыйбадәт бүлмәсендә намазлар укый, татар дин галимнәренең хезмәтләрен өйрәнә, Рамазан ае дәвамында уразалар тотып, авыз ачу мәҗлесләре уздыра, Коръән укучылар бәйгесе үткәрә. Очрашу алдыннан Татарстан мөфтие колониядә җәза үтәүче дин кардәшләребезнең татар рухи мирасын өйрәнүләре һәм нәшрият эше белән шөгыльләнүләрен үз күзләре белән күрде. Мисал өчен, кечкенә форматта әзерләгән дога китаплары, каллиграфиягә караган хезмәтләр Камил хәзрәттә зур кызыксыну уятты. Моннан тыш, тоткыннар тарафыннан кыска һәм аңлаешлы форматта тәһарәт алу һәм намаз уку буенча буклетлар эшләнгән, татар дин галимнәренең гыйбрәтле сүзләре диварга язылып куелган.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин очрашуны Аллаһының бөек Китабы – Коръән-Кәрим сүзләре белән башлап җибәрде. Ул дөньядагы барлык китаплар бары бер китапны – Коръәнне аңлау өчен язылганлыгы турында искәртте һәм төрмәдә булган вакытта мөмкин кадәр күбрәк аятьләр, сүрәләр ятларга чакырды: “Сез биредә тормыш мәшәкатьләреннән азат, шуңа Коръәнне ятлау һәм укуга зур әһәмият бирегез. Мәзһәбебез Коръәнгә нигезләнә. Кайсы гына дини мәсьәләне алсак та, Коръән нәрсә эшләргә, ә Сөннәт аны ничек эшләргә икәнлекне өйрәтә. Мәсәлән, Коръән намаз укырга, ураза тотарга, зәкят бирергә, хаҗ кылырга куша, ә Сөннәт ярдәмендә без бу гамәлләрне ничек башкарырга кирәклеген беләбез. Барлык дини һәм дөньяви фәннәр дә Коръәнгә барып тоташа. Шунлыктан, Коръәнне өйрәнегез”. Камил хәзрәт нәзарәт тарафыннан әзерләнгән татар һәм рус телләрендәге Коръән тәфсирләрен бастырганнан соң, республика төзәтү учреждениеләренә җибәрү күздә тотылуын да әйтеп узды.

Очрашу, гадәттәгечә, сорау-җавап рәвешендә барды. Күп сораулар намаз уку тәртибенә кагылышлы булды, берничә кардәшебез шулай ук гарәп хәрефләрен дөрес әйтү буенча мөфтидән дәрес алды: “Гарәп авазларын бөтен кеше дә әйтә ала, сез моның өчен бар тырышлыгыгызны куярга тиешсез. Коръәнне эчтән уку – ул беркем ишетмәслек итеп пышылдап кына уку дигәнне аңлатмый, аятьләрне эчтән укыганда да сез үзегез укыганны ишетергә тиешсез”. Моннан тыш, мөфти хәзрәттән дога кылу тәртипләре турында белеште. Камил хәзрәт: “Дога ул – Аллаһыдан сорау, үтенү дигән сүз. Әлбәттә, доганы нинди телдә дә кылсаң дөрес. Безнең динебездә иң мөһиме – ният”, – дип җавап бирде.

Әлеге очрашуда барлыгы утызга якын тоткын катнашты, Камил хәзрәт барлыгы дистәдән артык сорауга җавап бирде. Тоткыннар үгет-нәсыйхәт очрашуын оештыручыларга, барлык тудырылган мөмкинлекләр өчен мөфтигә тирән рәхмәтләрен җиткерделәр.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән берлектә 2016 елдан республикабыз төрмәләрендә җәза үтүче мөселманнар белән зур эш алып бара. Әлеге юнәлеш колонияләрдә экстремизм күренешләрен кисәтү максатыннан тормышка ашырыла. Нәтиҗәдә Татарстан Республикасының барлык төзәтү учреждениеләрендә гыйбадәт бүлмәләре яки мәчетләр эшли, аларда махсус әзерлекле имамнар хезмәт куя. Алар тоткыннарны дини яктан тәрбия кылу белән шөгыльләнәләр: вәгазьләр укыйлар, дини сорауларга җавап бирәләр, Коръән укырга өйрәнергә ярдәм итәләр. Дин әһелләре белән очрашулар һәр атна саен Татарстанның барлык төрмәләрендә уза. Төрмәләргә Нәзарәтнең “Хозур” нәшрияты тарафыннан дини әдәбият, Рамазан ае һәм Корбан бәйрәме уңаеннан күчтәнәчләр тапшырылып тора.

■ dum.rt

# Мөфтият вәкилләре Мәскәүдә казыятләр эшчәнлегенә багышланган семинарда катнашты

16 июль көнне Мәскәүдә «Хәзерге Россиядә Ислам хокукы культурасы: торышы һәм перспективалары» дип исемләнгән фәнни-гамәли семинар уздырылды. Чарада Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбәрәков катнашты. Семинар Ислам мәдәнияте, фәнне һәм мәгарифенә ярдәм итү фонды тарафыннан оештырылды.

Үзәкләшкән дини оешмалар, дәүләт органнары вәкилләре һәм экспертлар катнашында узган әлеге фәнни чара кысаларында Россиядә шәригать судлары практикасы турында фикер алыштылар. Аерым алганда, Җәлил хәзрәт Фазлыев казыйлар өчен бердәм кагыйдәләр кертү зарурлыгына игътибарны юнәлтте һәм Россиякүләм Казыйлар шурасын булдыру тәкъдиме белән чыкты. Булат хәзрәт Мөбәрәков исә Россиянең хокукый мәйданында шәригать хөкемнәрен куллану юллары, шәригать хөкемнәре чыгарганда казыйларның нинди документларга мөрәҗәгать итәлуы турында сөйләп узды.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: Татарстанда Казыйлар шурасы Россия төбәкләре арасында беренчеләрдән булып барлыкка китерелде. ТР мөселманнары Диния нәзарәте казыятләрнең шактый нәтиҗәле системасын булдырырга ирешә – ул Үзәк Россиядә иң яхшылардан санала. Казыят системасы республикабызның барлык территориясен колачлаган 7 төбәк зонасына бүленгән (Төньяк төбәк, Башкала төбәге, Төньяк-көнбатыш төбәк, Көньяк-көнбатыш төбәк, Көньяк төбәк, Көньяк-көнчыгыш төбәк, Көнчыгыш төбәге, Төньяк-көнчыгыш төбәк, Кама арьягы төбәге). Бу Россия өчен уникаль эш форматы, бары тик безнең республикада гына мөселманнар белән эш-ләүнең шундый бербөтен системасы төзелгән.



Шул ук вакытта Казыйлар шурасы әгъзалары 2018 елда үз эшләрен квартал саен һәм ситуацияне хәл итүгә ихтыяҗ туугa бәйле рәвештә уздырылган күчмә утырышлар форматында дәвам иттерде. Казыйлар тарафыннан гаилә һәм никах мөнәсәбәтләренә, бизнестагы бәхәсләргә, шулай ук милекне һәм мирасны бүлүгә кагылышлы эшләр каралды. Бүген Татарстанның барлык мөэмин-мөселманнары өчен казыйлар карары үтәргә мәҗбүри булган абруйлы сүз булып тора. 2018 елда Казыйлар шурасы халыктан кабул ителгән барлыгы 500 мөрәҗәгатьне карады. Моннан тыш, гаиләне саклап калу һәм икътисади мөнәсәбәтләр буенча тагын 900 дән артык консультацияне казыйлар телефон элемтәсе аша биргән.

■ dum.rt

# Корбан бәйрәме – 2019

2019 елның 11 августында бөтен дөнья мөселманнары төп бәйрәмнәрнең берсе – Корбан бәйрәмен (Гыйд әл-адха) каршы алачак. Ел саен ул Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә билгеләп үтелә. Шулай итеп, 2019 елда Корбан бәйрәме 11 августка туры килә.

Казан һәм Татарстан мәчетләрендә бу көнне бәйрәм вәгазе иртәнге 4:00дә башлана. Гает намазы 04:30 сәгатьтә. Башка шәһәр һәм авылларда гает намазы һәм вәгазе вакыты кояш чыгу вакытына карап билгеләнәчәк.

Татарстан Республикасының Казыйлар шурасы карары белән нисаб күләме, барлык чыгымнардан һәм әҗәтләрдән тыш, 20 000 сумны тәшкил итә.

Казанда корбан чалу бәйрәм намазыннан соң башланып китәчәк һәм махсус корбан чалу урыннарында өч көн дәвам итәчәк.

### Мәчет: адрес, телефон

1. «Казан Нуры» Фатыйх Әмирхан ур., 3 523-16-55, 523-14-95
2. «Салихҗан» Бестужев ур., 66а 513-66-50, +7 939 393-29-26
3. «Әл-Мәрҗани» Каюм Насыйри ур., 17 293-36-86, +7 937 284-19-02
4. «Гадел» Оренбург проезды, 193 269-50-37
5. «Ризван» Хөсәин Мәүлетов ур., 48а 224-38-47
6. «Апанай» Каюм Насыйри ур., 27 293-42-92
7. «Тынычлык» Мелитопольская ур., 15 (Тынычлык) +7 927 249-56-67, +7 904 767-81-61
8. Бертуган Петряевлар урамындагы комплекс Бертуган Петряевлар урамы
9. «Ярдәм» Серов урамы, 4а 223-03-59, 223-03-75, +7 904 760-99-50
10. «Рамазан» Окольная урамы, 25б 260-03-13, +7 952 149-53-77
11. «Мәүлид» Селянская урамы, 23 (Залесный)
12. «Җомга» Ильич урамы, 4
13. «Коддус» Яснополянский тыкрыгы, 16 (Карьер) +7 937 776-07-74
14. «Иман Нуры» Дорожная урамы, 32а (Нагорный) +7 987 226-03-13
15. «Дин-Ислам» 262-30-88, +7 903 305-59-34
16. «Билал» Иркен урамы, 29 (Вознесенское) +7 937 280-84-35
17. «Фатиха» Рихард Зорге урамы, 4а, (Кадышево) +7 927 245-66-72
18. «Рәҗәп» Энгельс урамы, 20

# Татарстан мәдрәсәләрендә кабул итү кампаниясе эшли

Татарстан Республикасының мөселман уку йортларында кабул итү кампаниясе бара. Татарстанда мәгариф системасы өч баскычтан тора: башлангыч, урта һәм югары. Башлангыч белемне мәчет каршындагы курсларда алып булса, урта белемне мәдрәсәләр, югары белемне Россия ислам институты, Казан ислам университеты (бакалавриат, магистратура) һәм Болгар ислам академиясе (магистратура, докторантура) бирә.

## “Ютазы” мөхтәсибәте укырга чакыра

Урыссудагы “Фәнис” мәдрәсәсе 2019-20 елларга тулы һәм тулы булмаган урта белемле укучылар (егетләр һәм кызлар) кабул итә.

Шәригать факультетына әңгәмә аша кабул ителә. Укыту рус телендә башкарыла.

Мәдрәсәдә барлык уңайлыклары булган тулай торак бар һәм 3 тапкыр ашау каралган.

Мәдрәсәне тәмамлаучы иргетләр “Имам-хатыйб, ислам дине фәннәре һәм гарәп теле укытучысы”, хатын-кызлар “Ислам дине фәннәре һәм гарәп теле укытучысы” дигән белгечлек алалар.

**Уку вакыты:**
Көндезге бүлек – 3 ел.
Читтән торып уку – 4 ел.

Тулы булмаган урта белемле укучылар мәдрәсәдә уку белән бергә параллель рәвештә мәктәптә 10 һәм 11 нче сыйныфта да укый алалар.

“Фәнис” мәдрәсәсен тәмамлаучы шәкертләргә имтиханнарсыз Россия ислам институтының 3 нче курсына укырга керү мөмкинчелеге дә бар.

Шәкертләрне бай һәм тирән эчтәлекле укыту программасы көтә: фикһ, гакыйдә, хәдис гыйлеме һәм башкалар. Аларның барысы да танылган хезмәтләр нигезендә укытылачак.

Кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:
– тулы яки тулы булмаган урта белем турындагы аттестат;
– 086 формасы буенча медицина белешмәсе;
– фото 3х4 (6 шт);
– паспорт, СНИЛС, ИНН, мед.полис копияләре;
– автобиография;
– гариза.

Телефон: +79270473328, Гәбделхәким хәзрәт, уку-укыту буенча директор урынбасары.

# Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы имамнарга татар телен белүне квалификацион таләп итеп өстәргә тәкъдим итте

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Аксакаллар шурасының чираттагы утырышында көн тәртибендәге төп сорауларның берсе буларак мөфтият компетенцияләре кысаларында татар милли үзенчәлеген саклау буенча эшчәнлек өлкәсендә чараларны көчәйтү мәсьәләсе каралды. Киңәшмәдә катнашучылар мәчетләрдә татар теле мохитен киңәйтү заруриятен ассызыклады. Алар фикеренчә, дөрес оештырылган һәм шул шартларда булдырылган табигый тел мохите мәчетләргә йөрүчеләр өчен татар телен үзләштерергә этәргеч бирәчәк. Моның өчен Аксакаллар шурасы әгъзасы Минвасил хәзрәт Шәфигуллин Татарстан имамнарына “Шәһадәтнамә” биргәндә квалификация таләпләрен тулыландыру тәкъдиме белән чыкты: татар телен белүне мәҗбүри итү. “Шәһадәтнамә” имамның ТР мөфтияте тарафыннан дини эшчәнлек алып баруга хокукын раслый торган төп документ булып тора. Татар телен белү имамнарга дини эшчәнлекне оештыру буенча гына түгел, җәмгыятьтә республикада милләтара татулыкны саклау мәсьәләсенә карата игътибар һәм кызыксынуны арттыруга юнәлтелгән агарту, социаль яктан әһәмиятле, тәрбияви, балалар һәм яшьләр башлангычларын гамәлгә ашыру буенча эшне дә нәтиҗәлерәк алып барырга мөмкинлек бирә.



Аксакаллар Минвасил хәзрәт Шәфигуллинның тәкъдимен хуплап чыкты һәм бу мәсьәләне ТР мөселманнары Диния Нәзарәте Пленумында раслату өчен мөфтият Президиумы әгъзалары карамагына тапшыру турында карар кабул итте.

■ dumrt.ru

# Комсызлык

### Бер кыйсса

Ислам дине килгәнче, җәһилият чорында ике туган яшәгән. Бервакыт алар юлга кузгалганнар. Күпмедер юл үткәч, кыя итәгендәге агач күләгәсендә ял итәргә туктаганнар. Ял итеп алганнан соң, юлларын дәвам итәргә дип кузгалырга теләгәндә, кыя астыннан авызына алтын капкан елан шуышып чыккан. Шул алтынны бертуганнар алдына куйган. Шунда бу ике туган бер-берсенә: "Мөгаен, монда бер хәзинә яшеренгәндер", – дип әйтәләр дә, юлларын дәвам итү уеннан кире кайталар. Алар бу җирдә өч көн һәм өч төн булалар. Һәр көн саен елан туганнарга алтын китергән. Шунда туганнарның берсе икенчесенә: "Без кайчанга хәтле бу еланга карап торачакбыз. Әйдә, аны үтерик, аннан хәзинәне казып чыгарырбыз һәм барлык байлыкны да үзебезгә алырбыз", – дип әйткән. Икенчесе исә аны бу фикереннән кире кайтарырга тырышып болай дип әйткән: "Син каян беләсең? Бер-бер хәл булып, син хәзинәне таба алмасаң?"

Ләкин беренче туган аның сүзен тыңламаган. Кулына балта алып, еланның чыкканын көткән. Елан күренүгә, ул аңа балта белән суккан, ләкин аның башы гына яраланган, ул үлмәгән. Елан куркып, бу туганга ташланган һәм чагып, аны үтергән, үз өненә кереп киткән. Икенче туган үзенең абыйсын күмгән һәм бу төнне шунда кунарга калган.

Икенче көнгә елан үз өененнән шуышып чыккан, ләкин авызында бернәрсә дә булмаган. Шул вакытта туганнарның исән калганы еланга болай дип әйткән: "Әй, елан! Аллаһы белән ант итәм, синең белән булган хәлләргә мин каршы идем. Туганымны уйлаган фикереннән кире кайтарырга теләдем, ләкин ул мине тыңламады. Аллаһы шаһит булсын, әйдә синең белән яңа килешү төзик, син миңа зыян китермә, мин дә сиңа начарлык эшләмәм. Син миңа элеккеге кебек көн саен алтын китер". Елан аңа: "Юк, болай булмый. Син абыеңның каберен күреп, мине күрә алмый башлаячаксың. Мин исә, башымдагы яраны искә төшереп, сине дошман күрермен", – дип әйткән.

### Нәсыйхәт

Саранлык – бик начар сыйфат. Әгәр дә беренче туган саран булмаса, алар көн саен алтын алырлар иде. Саранлыгы һәм комсызлыгы сәбәпле, ул алтыннан да коры калды һәм аның гомере дә өзелде.

Мөмкин булганча кеше иң күркәм рәвештә начарлыкка каршы торырга тиеш. Әгәр дә ул моны эшли алмаса, үзе начарлык кылучылардан булмасын.

# Ризык Аллаһы Тәгаләдән

### Бер кыйсса

Хәбиб Әҗәминең хатыны акча эшләсен дип, гел ирен ялланып эшләргә куа торган булган. Аның бик тә байлыкта һәм мул тормышта яшисе килгән. Көннәрдән бер көнне Хәбиб Әҗәми хатынының бу үзсүзлегеннән арып, иртән өеннән чыгып киткән һәм бер аулак җиргә барып урнашкан. Анда кичкә кадәр гыйбадәт кылган. Кичен бернәрсә дә алып кайтмаган ирен күргәч, хатыны: "Нәрсә булды? Син бернәрсә дә сатып алмагансың, акча да алып кайтмагансың. Әллә син бүген эшләмәдеңме?" – дип сорау биргән. Ире хатынына: "Мин бүген бик бөек һәм юмарт булганга хезмәт иттем һәм шуңа да аннан хезмәт хакы сорарга оялдым", – дип җавап биргән.

Шулай өч көн дәвам иткән. Хәбиб Әҗәми иртән өеннән чыгып киткән, көне буе гыйбадәт кылган. Кичен буш кул белән өенә кайтып, хатынының сорауларына шундый ук җаваплар кайтарган. Өченче көн кичен хатынының бу хәлләргә сабырлыгы бетеп, түзмәгән, иренә болай дип әйткән: "Йә син хезмәт хакын сорыйсың, йә башка берәүгә ялланып эшкә барасың, йә мине аер".

Хәбиб Әҗәми иртән, гадәттәгечә, өеннән чыгып киткән. Кичен өенә кайтып кергәч, тәмле ризык исе борынына бәрелгән. Хатыны бик шатлыклы йөз белән ирен каршы алган һәм иренә: "Син ялланып эшләгән хуҗаң безгә бик күп ризык һәм бер янчык алтын җибәргән", – дип әйткән. Бу сүзләрне ишеткәч ире елап җибәргән һәм хатынына болай дип әйткән: "Болар барысы да иң юмарт булган Аллаһы Тәгаләдән".

Шуннан соң аның хатыны бик үкенгән һәм башка иренә мондый теләкләрен белдермәскә сүз биргән.

### Нәсыйхәт

Берәр кешегә ялланып, акча эшләү рөхсәт ителсә дә, Хәбиб Әҗәми Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуны өстенрәк күргән. Сабырлык кылып, катлаулы мәсьәләләрне чишәргә һәм теләгәнеңә ирешергә мөмкин.

Шунысын да онытмыйк, ир-атка гаиләсен ризык, тормыш кирәк-яраклары белән тәэмин итү фарыз булып тора. Бу кыйссадан Хәбиб Әҗәми бөтенләй гаиләсен тәэмин итмәгән дигән фикер туарга тиеш түгел. Ул гаиләсенең ихтыяҗларын канәгатьләндергән. Бары тик хатыны гына бик күп малга кызыккан һәм иреннән гел эшкә чыгуын таләп иткән.

# Җәяүле

### Бер кыйсса

Бервакыт Ибраһим бине Әдһәм җәяүләп хаҗга юл тоткан. Юлында аңа дөягә утырган бер җайдак очраган. Җайдак Ибраһим бине Әдһәм куддисаллаһу сирруһудан: "Әй карт! Кая юл тотасың?" – дип сораган. "Мин Кәгъбәгә барам", – дип җавап биргән Ибраһим бине Әдһәм. Җайдак моңа гаҗәпләнеп, аңа болай дип әйткән: "Син анда ничек барып җитәрсең соң? Синең бит атланып барырга бернинди хайваның да юк". Ибраһим бине Әдһәм аңа: "Нигә булмасын. Минем хәрәкәт итәргә төрле мөмкинчелекләрем бар", – дип җавап биргән. Тегесе аны аңламыйча: "Нәрсәләр соң алар?" – дип сораган. Ибраһим бине Әдһәм аңа хикмәт белән болай дип җавап биргән: "Әгәр дә минем белән берәр бәла-каза булса, мин сабырлыкка утырам. Миңа берәр игелеклелек бирелсә, мин рәхмәткә утырам. Минем белән хәерле нәрсә булса, мин шөкергә утырам. Әгәр минем нәфесем мине берәр нәрсәгә чакырса, мин калган гомеремнең яшәлгән гомеремнән аз калганын исемә төшерәм дә, шуннан чыгып хәл итәм". Моны тыңлап торган җайдак: "Син чын җайдак, ә мин – җәяүле икәнмен. Юлларың һәм сәфәрең имин булсын", – дип әйткән.

### Нәсыйхәт

Без бер урыннан икенче урынга күчкән вакытта төрле хәрәкәт итү чараларын кулланган кебек, Аллаһының ризалыгына ирешү өчен дә билгеле бер рухи чаралар бар.

Әгәр дә кеше белән берәр бәхетсезлек булса, ул сабырлыкка утырсын, ягъни бу хәлгә сабырлык кылсын. Коръәндә әйтелә:

**«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. Сабыр итүчеләрне сөендер!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155



**«Сабыр итүчеләрнең әҗере хисапсыз биреләчәк».**

«Зөмәра / Халык Төркеме», 39:10

Әгәр кешегә ниндидер игелеклелек ирешсә, ул рәхмәткә утырырга тиеш, ягъни моның өчен рәхмәт, шөкер кылырга. Шөкер иткән саен игелеклелек тагын да артачак. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

**«Раббыгыз: «Әгәр шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә арттырачакмын. Әгәр рәхмәтле булмасагыз, һичшиксез, Минем газабым бик каты», – дип игълан итте».**

«Ибраһим», 14:7

Әгәр дә кеше белән берәр нәрсә булса, моны Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән булуын кабул итәргә һәм тәкъдиргә риза булырга кирәк.

■ "Рухуль-Бәйан" китабыннан тәрҗемәләр

# Бәхетле һәм ныклы гаилә сере: ир белән хытынга 12 киңәш

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе риваять итә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: "Сезнең һәрберегез – көтүче һәм һәрберегез үз көтүегез өчен җаваплы: ир-ат үзенең якыннарына мөнәсәбәтле көтүче һәм алар өчен җаваплы; хатын-кыз иренең өенә һәм аның балаларына мөнәсәбәтле көтүче һәм дә алар өчен җаваплы". Ир белән хатынның гаиләдә һәрберсенең үз җаваплылыгы бар. Бәхетле һәм гармонияле гаилә тормышы шуңа бәйле дә инде. Бу уртак максатка ирешү өчен ир-ат та һәм дә хатын-кыз да үз өлешен тиешенчә башкарырга тиеш. Шуны да онытмыйк, гаилә ул – көндәлек хезмәт. Һәркем бу өлкәдә үз тырышлыгын куярга тиеш, шул чагында гына гаиләнең тамыры нык булыр. Бу уңайдан кайбер киңәшләрне карап үтсәк артык булмас.



## Иргә киңәшләр:

1. Хатыныгызга карата яхшы мөнәсәбәттә булыгыз. Гаилә башлыгы булу – гаилә әгъзаларын куркытып, залим булу түгел. Ул аларны кайгырту һәм алар өчен җаваплы булу, аларның кимчелекләрен күрсәң дә, сабыр итү.

2. Парыгызны хөрмәт итегез. Аның үз фикерен әйтергә, үз тормышына хокукы бар. Берәр нәрсә белән кызыксынып, шөгыльләнергә теләсә, аннан көлмәгез, киресенчә, бу башлангычында аңа терәк булыгыз.

3. Хатыныгыз белән дорфа булмагыз, аңа тавыш (бигрәк тә кул) күтәрмәгез. Кайбер ирләр дуслары, хезмәттәшләре, әти-әнисе белән үзен яхшы тоталар, ә хатыны һәм балаларына карата дорфа булалар. Гаилә әгъзалары белән дә яхшы мөнәсәбәт урнаштырыгыз. Алар сезнең эштән кайтуыгызны куркып түгел, ә зарыгып көтәрлек булсын.

4. "Хатын-кызлар колак белән ярата" диген гыйбарәне онытмагыз. Шуңа да ярату сүзләрен кызганмагыз. Аны башкалар белән дә чагыштырмагыз. Сез бит аны үзегез сайлап алдыгыз, шуңа да хөрмәт итеп, кадерен белегез.

5. Гаилә һәрнәрсәдән дә (дуслардан, яраткан шөгыльләрдән) өстен булырга тиеш. Гаилә хәлләрен дустыгызга сөйләмәгез.

6. Хатыныгызның тышкы кыяфәтендәге һәм үз-үзен тотышындагы үзгәрешләргә игътибарлы булыгыз. Сезне шатландырыр өчен яңа күлмәк кисә яки берәр ризык әзерләсә, үзегезнең шатлыгыгызны белдерергә онытмагыз.

7. Үзегезнең тышкы кыяфәтегез турында да онытмагыз, аны һәрвакыт тәртиптә тотыгыз. Өйдә, якыннарыгыз янында булсагыз да, киемнәрегезгә игътибарлы булыгыз. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: "Миңа хатынымның минем өчен бизәнүе ошый, шуңа мин дә аның өчен бизәнергә яратам".

8. Хатыныгызга йорт эшләрендә ярдәм итүдән читенсенмәгез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу гамәлне үзенә түбәнчелек итеп санамаган.

9. Бик еш булмаса да, ара-тирә хатыныгызга зур булмаган бүләкләр алыгыз. Ул берәр бизәнү әйбере буламы яки берәр чәчәкме, ләкин кечкенә булса да, кешенең күңелен күрергә ул да җитә. Хәдистә әйтелә: "Берберегезгә бүләкләр бирешегез, ул сезнең арада мәхәббәтне арттыра».

10. Әгәр дә хатыныгызга кисәтү ясарга теләсәгез, аны чит кешеләр янында түгел, бары тик икәүдән-икәү калганда гына әйтегез. Әйткән очракта да, йомшак кына, кешене түбәнсетеп түгел. Хатыныгызны балалар алдында тәнкыйтьләмәгез, аларда әнигә карата хөрмәт булырга тиеш.

11. Әти-әниегез һәм хатыныгыз белән мөнәсәбәтләрдә чама хисен югалтмагыз. Хатыныгызны артыграк яратып, әти-әниләрегезне үпкәләтеп, алар белән элемтәләрне өзмәгез. Шулай ук әти-әниләрне ярату сәбәпле хатыныгызны да үпкәләтергә кирәкми.

12. Ислам дине ир кешегә талак хокукы бирә. Ләкин сәбәпле яки сәбәпсез килеш бу хокук белән файдаланып, хатынны гел куркытып, мыскыл итәргә ярамый.

## Хатынга киңәшләр:

1. Ирегез өчен патшабикә буласыгыз килсә, аның үзен дә патша урынына күрегез. Эштән кайтканда аны ягымлы йөз, тәмле тел белән каршы алыгыз. Тышкы кыяфәтегезгә дә игътибарлы булыгыз.

2. Иregезгә ул яраткан тәмле ризыкларны әзерләгез. Әгәр иregезгә берәр үтенечегез бар икән, аның тамагы ач вакытында әйтмәвегез хәерле.

3. Ир-атка гына түгел, хатын-кыз иренә кечкенә генә булса да сюрпризлар әзерләсә, бүләкләр бирсә хәерле. Бүләкнең кыйммәтле булуы мөһим түгел, ә игътибар, хөрмәт мөһим.

4. Гаилә тормышында бәхәсләр дә була. Ләкин аларны тыныч кына, берберең[ә] юл куеп, начар сүзләр әйтмичә, түбәнсетмичә хәл итәргә кирәк.

5. Ирегезне үткәндәге хаталары һәм ялгыш гамәлләре өчен битәрләмәгез.

6. Ирегезгә яхшы дус һәм терәк булырга тырышыгыз. Ул сезнең белән үзенең киләчәккә планнары, хыяллары белән уртаклашсын; авыр вакытларында сезнең белән киңәшләшсен, аларны яшермәсен.

7. Ирегез гаиләсенә һәм сезнең өчен эшләгән һәрбер игелеге өчен аңа рәхмәтле булыгыз. Гаиләсен тәэмин итүдә тырышлыгы, йорт эшләрендә ярдәм итүе, балалар белән шөгыльләнүе өчен аны мактагыз.

8. Ирегезнең әти-әниләре белән яхшы мөнәсәбәттә булыгыз, аларны тәнкыйтьләмәгез.

9. Ирегезнең ниндидер шөгыльләренә (спорт чаралары, машиналар белән кызыксыну, балыкка йөрү һ.б.) каршы килмәгез.

10. "Тавышны өйдән чыгарырга" кирәкми. Сезнең гаиләгезгә бәйле хәлләр гаиләдә калсын. Сез ирегез белән әрләшсәгез дә, аны әниегезгә, туганнарыгызга, иптәшләрегезгә сөйләмәгез. Сез күпмедер вакыттан соң ирегез белән аңлашырсыз, ләкин ул кешеләрдә ирегезгә карата начар фикер калуы бар.

11. Әлбәттә, сәер яңгыраса да, ире хатынга балаларына караганда да якынрак булырга тиеш. Балалар озак тормый буйга җитәләр дә, үз гаиләләре, тормышлары белән яши башлыйлар. Әти-әнинең төп максаты да – балаларны мөстәкыйль кешеләр итеп тәрбияләү. Ир белән хатын бигрәк тә картлык көннәрендә берберләренә терәк булалар.

12. Балаларыгызда әтигә карата хөрмәт, ихтирам тәрбияләгез. Алар булганда аны яманлап сүз әйтмәгез. Балалар сезнең бәхәсләрнең, тавышларыгызның шаһитлары булмасыннар. Шулай ук ирегезнең ялын да саклагыз, балалар аңа эштән арып кайткач ял итәргә комачау итмәсеннәр.

Аллаһы Тәгалә үзара аңлашучанлык урнаштырып, һәрбер парга гаилә бәхете насыйп итсә иде.

■ Islam-today.ru

# Аллаһыга шөкер кылып, рәхмәтле булып яшәү

Җир-күкләрне яратып, яңгырлар яудырып, шуның белән безгә барлык җимешләрен дә ризык итеп тәкъдим кылган, безне төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.



Аллаһы Раббыбыз Җирне һәм күкләрне, алар арасында булган барча мәхлукатны нинди гүзәл итеп яраткан. Адәм балаларын акыл белән зиннәтләп, нинди гүзәл, камил сурәттә бар кылган. Шушы гүзәллекне күрү, тою, шул гүзәллек эчендә яшәү бәхет түгелме? Аллаһының бетмәс-төкәнмәс нигъмәтләренә без шөкер кылырга тиеш түгелме?

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләре бихисап. Болар – кояш, сулаган һавабыз, һәр сулыш алуыбыз, акыл, сәламәтлек, ашаган ризыгыбыз, кигән киемнәребез һәм безнең әйләнә-тирәбездә булган бик күп башка нигъмәтләр. Ни кызганыч, күбебез әле моны Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләре булуын танымый, шулай тиеш, дип кабул итә.

Коръәни Кәримдә шөкер итү буйсынучанлыкның төп билгесе булуы һәм Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә шөкер итмәгәннәрнең шелтәләнүе хакында әйтелә. Мәсәлән, Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә Аллаһы Тәгалә: **“Аллаһы сезне аналарыгызның карыныннан чыгарды, ул вакытта һичнәрсә белми идегез. Сезгә колак, күз вә күңел бирде, шулар белән белә башладыгыз, шуларны уйласагыз, шаять, шөкер итәрсез!»** – дип әйтә.

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:78

## Нәрсә ул шөкер?

Шөкер итү – кешенең үз хәленнән канәгать булып, Аллаһыга рәхмәтләрен белгертүедер. Аллаһы Тәгалә кешеләргә санаусыз нигъмәтләр биргән. Ашау-эчүләребезне дә бар иткән, саулыкта яшәткән бөек зат – Аллаһы Тәгалә. Акыл, рух, гәүдәбезгә көч-куәт биреп, төрле эшләрне башкарырга мөмкинлек кылучы да – Аллаһы Тәгалә. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: **“Әгәр Аллаһының биргән нигъмәтләрен санап карасагыз, һич санап бетерә алмассыз. Шиксез, Аллаһы ярлыкаучы вә рәхимле».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:18

Бу аяткә биргән аңлатмасында Ибне Җәрир: “Тәхкыйк, әгәр дә сез түбәнчелек һәм Аңа буйсынуга омтылу белән килсәгез һәм Ул риза булырлыкны эшләсәгез, кайбер нигъмәтләренә Аңа рәхмәтләрегезне әйтергә онытсагыз, Аллаһы Тәгалә сезне ярлыкар, чөнки Ул сезгә рәхимле-шәфкатьледер”, – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кешенең гыйбадәте – Аллаһы Тәгаләгә бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итүе», – дип әйткән. Бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итү сүзләр белән генә түгел, ә шул нигъмәтләрне кулланып та белдерелергә мөмкин. Байлык өчен шөкер итү мохтаҗларга ярдәм итү аша белдерелә, белемнәр өчен шөкер итү шул гыйлемнәрне кешеләр файдасына куллану аша, ә сәламәтлек өчен гыйбадәтләр кылып, хезмәт итеп рәхмәтебезне белдерә алабыз.

## Шөкер кылу өч төрле була

Беренче шөкер төре – йөрәк белән шөкер итү. Йөрәк белән шөкер итү – ул барлык игелекләрнең дә Аллаһы Тәгаләдән икәнлеген аңлау. Аллаһы Тәгаләдән ирешкән һәрбер нәрсәгә (хәтта аз күләмдә булса да) без рәхмәтле булырга, шөкер итәргә тиешбез. Бер риваятьтә: "Игелекнең аз күләмдә булуына түгел, ә шушы игелекне сиңа биргән Аллаһы Тәгаләнең Бөеклегенә игътибар ит", – дип әйтелгән. Йөрәк белән шөкер итү – Аллаһы Тәгалә биргән һәр нигъмәткә канәгать булу дигән сүз. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: “Үзегездән яхшырак хәлдә булган кешеләргә түгел, ә сезнекенә караганда начаррак хәлдә булганнарга карагыз”, – дип әйткән (имам Мөслим).

Икенчесе – тел белән шөкер итү. Тел белән шөкер итү – ул барлык нәрсәнең дә Аллаһы Тәгаләдән икәнлеген тану дигән сүз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: “Аллаһы колына бер нигъмәт биреп, ул “Әлхәмдүлилләһ” дип әйтсә, ул шөкер иткән булыр. Әгәр кеше икенче мәртәбә дә “Әлхәмдүлилләһ” дип әйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең савабын арттырыр, өченче тапкыр кабатласа, гөнаһларын гафу итәр”, – дип әйткән.

Өченчесе – әгъзалар белән шөкер итү. Намаз уку, ураза тоту, хаҗ кылу кебек гыйбадәтләр белән бергә, динне аңлату, тарату һәм бу юлда хезмәт итү дә әгъзалар белән шөкер итүгә керә.

Аллаһы Тәгалә: **«Аллаһыдан башка сыннарга гыйбадәт кыласыз, вә сыннарыгызны Аллаһы дип ялган сөйлисез. Аллаһыдан башка гыйбадәт кыла торган сыннарыгыз сезгә ризык бирергә кадир (көчле) түгелләр. Ризыкны Аллаһыдан сорагыз вә Аңа гына гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа шөкер итегез, чөнки хөкем ителергә Аллаһыга кайтасыз»**, – дип әйтә.

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:17

Кояш чыгып сөңге буе күтәрелгәннән алып, өйлә вакыты кергәнче укыла торган ишракъ, духа намазлары да һәр буыныбыз өчен шөкер кылу булып тора.

Коръәни Кәримнең «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятендә Аллаһы Тәгалә шөкер итүчеләргә нигъмәтләрен арттырырга вәгъдә итә: **«...Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын...»**. Аятьнең дәвамында Ул бәндәләрен түбәндәге сүзләр белән кисәтә: **«Әгәр көферлек кылсагыз, Минем газабым бик каты»**.

## Шөкер кылуның билгеләре

Шөкер кылуның иң беренче билгесе – бу дөньяда да, Ахирәттә дә бөтен нигъмәтләрне бирүче һәм бөтен нигъмәтләрнең хуҗасы булган Аллаһыны тану, Аңа иман китерү. Аллаһыны танымау – иң зур гөнаһ. Аллаһыны танымаучы, бу дөньяда Аллаһының нигъмәтләрен башкалар белән тигез файдалана алса да, Аллаһының Ахирәттә әзерләнгән барча нигъмәтләреннән мәхрүм кала. Ул кешегә җәһәннәм газабыннан башка берни дә юк һәм аның хәлен беркем дә, бу дөньяда тупланган бернинди байлыгы да үзгәртә алмый. Андый кеше Аллаһының бу дөньядагы бер өлеш байлыгына алданып, 99 өлешеннән мәхрүм калучы була.

Шөкер кылуның икенче билгесе – бөтен тормышыңны Аллаһы кушканча көйләү, ягъни Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү. Аллаһыны танып та, Аллаһы кушканча яшәмәгән кеше, көферлеккә төшмәсә дә, зур гөнаһлы була. Ул Аллаһының олы нигъмәте булган җәннәтенә җәһәннәм газабы аркылы гына ирешә ала.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә: **“Ий мөэминнәр! Әгәр чын ышану белән ышанып, Коръән белән гамәл кылсагыз һәм нигъмәтләргә шөкер итсәгез, Аллаһы сезне ник газапларга тиеш соң? Шиксез, Аллаһы чын мөселманлыкның хакын җәннәт нигъмәтләре белән түләүче һәм һәрнәрсәне белүче булды»**, – дип әйтә.

«Нисә / Хатыннар», 4:147

Мөхтәрәм җәмәгать, безнең – мөэминнәрнең – бу дөньяда да саусәламәт буласыбыз, бәхеттә-нигъмәттә яшисебез килә. Ахирәттә дә җәннәтне өмет итәбез. Шушы ике дөнья бәхетенә ирешү өчен без Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә шөкер итеп яшәргә тиешбез. Шөкер итсәк, Ул безгә биргән нигъмәтләрне кире алмас, киресенчә, арттырып та кайтарыр. Коръәндә дә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: **«...Әгәр Аңа гыйбадәт кылып шөкер итсәгез, Ул эшегездән риза булыр»**.

«Зөмәрә / Халык Төркеме», 39:7

Хөрмәтле дин кардәшләрем, нәрсә генә эшләсәк тә, әлбәттә, Аллаһы ризалыгы өчен эшләү кирәк. Аллаһы риза булсын өчен тырышып тормышын алып баручы, башкалар сөенгәннән шатлык хисе кичерүче чын бәхетле кеше була. Барысына да канәгать булып, шөкер кылып, Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп булсын.


■ **ТҖ МДН Дәгъват бүлеге**

## Корбан чалу нәрсә ул?

**Сорау: Корбан чалу нәрсә дигәнне аңлата?**
**Җавап:** Ул хаҗ белән гомрәдә түбәндәге максатлар белән хайван сую:

1. Ихрамнан чыгу өчен;
2. Бер йоланы үтәү өчен (моны карин яисә мөтәмәттигъ үтәр);
3. Кәффарәт түләү өчен;
4. Үз ихтыярың белән Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен.

## Кайсы хайваннар корбан өчен ярый?



**Сорау: Корбан өчен нинди хайваннар ярый? Корбанлык хайваннарның нинди дә булса чикләмәләре бармы?**
**Җавап:** Корбан өчен дөя, сыер һәм сарык ярый. Ата яисә ана булса да – барыбер. Алар сәламәт вә кимчелексез, билгеле бер яшьтә булырга тиешләр.

**Сорау: Бу билгеле яшьнең чикләре нинди?**
**Җавап:** Сарык – бер яшь һәм аннан олы, сыер ике яшьтән олырак, дөя биш яшьтән олырак булырга тиеш. Әгәр дә 6 айлык сарык, бер яшьлек сарык кебек күренсә, шул да ярый.

## Сәламәт дип нинди хайванга әйтәбез?



**Сорау: Сарыкны сәламәт итеп санау өчен, ул нинди шартларга туры килергә тиеш?**
**Җавап:** Барлык әгъзалары да бөтен булырга тиеш, хәтта койрыгы, колаклары, күзләре дә. Әгәр койрыгының яки колагының аз өлешендә генә кимчелек булса, мондый хайванны корбанга чалырга рөхсәт ителә.

## Сыер һәм дөяне корбан итеп чалган очраклар

**Сорау: Кайчан корбанга сыерны яки дөяне чалырга кирәк?**
**Җавап:** Әгәр дә хаҗи зиярәт тәвафын җөнеб хәлендә кылса һәм тәһарәт кылганда кайтармаса, Гарәфәттә басып торганнан соң кырынуга вә зиярәт тәвафына кадәр якынлык кылса, сыер яки дөяне корбан итеп чалырга кирәк. Калган очракларда корбанга сарык китерсә дә җитә.

## Корбанны берничә кеше чалу ярыймы?

**Сорау: Берничә хаҗи бергәләшеп корбан чалсалар ярыймы?**
**Җавап:** Әйе, әгәр дә хаҗиның һәрберсе корбан чалырга теләсә, сыер белән дөяне бергә кушылып чалырга мөмкин.

**Сорау: Әгәр дә җиде корбан чалучыларның берсе корбанны фәкать ит өчен генә чалса, бу ничек бигеләнә?**
**Җавап:** Җидесенең дә корбаннары кабул булмый.

## Кәффарәт корбанының итен ашарга ярыймы?

**Сорау: Җиде корбан чалучының да корбанының итен ашарга рөхсәт ителәме?**
**Җавап:** Хаҗ йоласы итеп корбан чалган хаҗига корбанның итен ашау мөмкин, ә кәффәрат өчен чалынган корбанның итен ашау тыела.

## Кобан чалу вакыты




**Сорау: Корбан чалу өчен аерым вакыт билгеләнгәнме?**
**Җавап:** Хаҗ йоласы итеп, корбан чалу фәкать хаҗ көннәрендә генә (10 нчы зөлхиҗҗәдән алып 12 нче зөлхиҗҗәгә кадәр) үтәлә, тик хаҗ көнендә баганага таш бәргәнче рөхсәт ителми.

## Хаҗда корбан итен кая куярга?

**Сорау: Корбан итен Әл-Хәрамдагы фәкыйрьләргә таратырга ярыймы?**



**Җавап:** Таратырга ярый, Әл-Хәрамнан читтә булган фәкыйрьләргә дә рөхсәт ителә.

## Хайваннарны ни рәвешле чалырга?

**Сорау: Кайсы очракта чалырга (кадарга) һәм кайсы очракта суярга?**
**Җавап:** Дөяне чалу (кадау), сыер белән сарыкны сую – сөннәт.

**Сорау: Корбанлык хайванны үзеңә үзең чалу тиешме? Әллә мин аны башка бер кешегә дә тапшыра аламмы?**
Җавап: Моны башка берәүгә дә тапшырырга мөмкин, әгәр дә үзең әйбәт чалсаң, үзеңә эшләү хәерлерәк.

## Корбанлыкка атланып йөрергә ярыймы?

**Сорау: Корбанлык хайванга утырып йөрергә ярыймы? Корбанлык хайванны саварга ярыймы?**
**Җавап:** Әгәр дә моңа зарурлык булмаса, моны эшләмәү хәерлерәк.

Корбанлык хайванны саварга ярамый. Ләкин сөте җыелмасын өчен җиленен салкын су белән суытырга кирәк.

## Хайван кинәт кенә авырып китсә, нишләргә?

**Сорау: Әгәр дә корбанлык хайван юлда авырса яисә аңа кимчелек килсә, ягъни корбанга ярамаса, бу очракта нишләргә?**
**Җавап:** Әгәр дә корбанлык хайван өстәмә гыйбадәт кылу өчен булса, аны суеп, итен фәкыйрьләргә таратырга кирәк. Әгәр дә вәҗиб корбан өчен булса, аны сәламәт хайван белән алыштырырга кирәк.

## Корбан чалучыга ничек түләнелә?

**Сорау: Корбан чалучының эше өчен корбанлык ит белән түләргә ярыймы?**
**Җавап:** Юк, корбан чалучыга өстәмә түләргә кирәк.

■ **Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрнинең «Әт-Тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан**

# Мөселман яшьләре форумы – 2019

Болгар шәһәрендә сигезенче мөселман яшьләре форумы гөрләп узды. Быел ул 12-19 июль көннәрендә үткәрелде. Аллаһы рәхмәте белән миңа да бу чарада катнашырга насыйп булды.

Мөселман яшьләре форумы – тылсымлы бер дөньяга сәяхәт кылган кебек, чөнки иртәдән төнгә тикле синең яныңда бары тик мөселманнар гына, биш вакыт намазга матур азан яңгырый, күзең һәрчак хәләлне генә күрә һәм күңел тынычлыгы табасың.

Мөселман яшьләре форумы минем өчен ул кечкенә бер тормыш. Әмма ул тормыш шулкадәр күп сыешлы – үзенең эченә иң мөһим нәрсәләрне ала.

Мәсәлән, гыйлем алу. Мөселман кешенең күңеле һәрчак белем алуга омтыла. Форум кысаларында мөселман яшьләре өчен Коръән белән бәйле бик яхшы лекцияләр үтте. Остазларыбыз бик данлы галим шәех Габдеррахим Ләкрим, Әхмәт Әл-Хәнәфи һәм Некаддам остаз булды. Форумда алган дәресләр миңа Аллаһының Китабын өйрәнүдә бәя биреп бетергесез нык нигез салды, әлһәмдүлилләһ.

Форум – ул бары тик лекцияләр һәм дәресләр генә түгел, ул шулай ук кызыклы, мавыктыргыч чаралар да.

Күңелемә бик ошаган чараларга килгәндә, Җәлил хәзрәт Фазлыевның форумга кунакка килүе турында әйтеп үтәсе килә. Җәлил хәзрәт яшьләр белән бик мөһим темаларга әңгәмә корды: танышу, никах, мәһәр, талак һ.б. Форумда катнашучылар бу чарадан бик канәгать калды.

Бу елны оештыручылар тарафыннан ток-шоу форматында “Зорко одно лишь сердце” чарасы үткәрелүе яңа ачыш булды. Бу чара – өйләнергә теләгән яшь мөслимә кызлар һәм мөселман егетләре өчен иде. Оештыручылар форумда катнашучылар арасыннан биш кыз һәм биш егет сайлап, чараның кагыйдәләрен аңлатып әзерләделәр. Ток-шоу экспериментал рәвештә үтте һәм берничә этаптан торды. Беренче этапта яшьләр бер-берсен күрмичә, чаршау аша гына биремнәр үтәделәр, икенче этапта аларга бер-берсен күреп, танышырга рөхсәт булды.

Оештыручылар форумда катнашучылар өчен күп комитетлар ачканнар: “Хайповый”, “Сценический”, “Скорый”, “Хозяйственный”, “Небесный” һәм башкалар. Һәр комитетның үзенең зур бер максаты бар һәм форум дәвамында яшьләр шул максатка ирешергә тырыштылар.

Иң тылсымлы комитетларның берсе – ул “Небесный”. Форумга килеп җиткәннән бирле ул комитетның катнашучылары һәр кешенең теләкләрен тормышка ашырырга тырыштылар. “Небесный” комитет форумга йөзләгән бәхетле, куанычлы кеше бүләк итте.

Бик мөһим комитетларның тагын берсе – “Хайповый” булды. Бер атна дәвамында форумның бөтен социаль челтәрләре ул комитетның кулында иде. “Хайповый”лар форумда катнашучылар белән бәйле кызыклы мизгелләрне, чараларны төшереп бардылар. Ул комитет ярдәмендә күп кеше социаль челтәрләр аша форум тормышы турында хәбәрдар була ала иде.

Әгәр сез моңа кадәр үзегезгә: «Мөселман яшьләре форумына барырга микән?», «Ул кирәкле нәрсә микән?» – кебек сорауларны биргән булсагыз, җыенгыз һәм барыгыз. Бу чара бик көчле һәм эчтәлекле булды. Әгәр вакытны кирегә борып, үткәнгә кайтып булса, һәм миңа яңадан Болгарга килергә мөмкинлек бирсәләр, уйлап та тормый, әлбәттә: «Әйе!» – дип әйтер идем.

■ **Миңһаҗева Айгөл**










# «Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының укыту-тернәкләндерү үзәгендә «Сөйләшә торган куллар» проекты буенча курслар башланды

17 июльдән Казанда "Сөйләшә торган куллар" проекты буенча ун көнлек тернәкләндерү курслары башланып китте. Әлеге проект ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләрне тернәкләндерүгә юнәлтелгән.

"Ярдәм" милли ислам хәйрия фонды 2000 еллар башында үз эшчәнлеген ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр өчен курслар оештырудан башлап җибәргән иде. Бу эш әле дә дәвам итә. Алар өчен беренче тапкыр курслар 2004 елда Левченко бистәсендәге "Сөләйман" мәчетендә узды.

Тернәкләндерү курслары даими рәвештә оештырыла. "Сөйләшә торган куллар" проекты кысаларында ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр белем дә ала, тернәкләнү дә уза. Әлеге проектның нигезен алар өчен махсус эшләнгән белем бирү программасы тәшкил итә.

Ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр ислам нигезләрен "Ярдәм" милли ислам хәйрия фондының укыту-тернәкләндерү үзәге директоры Мәликә Гыйльметдинова тарафыннан эшләнгән методика буенча өйрәнә. Ул ишетмәүчеләрне һәм күрмәүчеләрне өйрәтү юнәлешендә танылган белгеч. 2007 елда Мәликә Гыйльметдинова ишарәләр телен өйрәнә һәм танылган татар дин галимнәре хезмәтләре буенча ишетмәүчеләр өчен "Ислам нигезләре" курсыннан белем бирү өчен махсус методика эшли.

Тернәкләндерү курсларында шулай ук компьютерда эшләргә, кул эшләренә өйрәтәчәкләр, йорт эшләре дәресләре узачак. Ишетмәүчеләргә ишарәләр телендә мөселман терминнары төшендереләчәк.



Ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр белән психологлар эшләячәк. Алар шулай ук массаж сеанслары алачак.

Тернәкләндерү курсларыннан тыш, уку елы дәвамында ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр өчен сурдотәрҗемә ярдәмендә рухи темаларга лекцияләр үткәрелә. Ә якшәмбе көнне алар Коръән укырга өйрәнә. Җомга вәгазе дә сурдотәрҗемә белән узачак.

■ dum.rt

# Нәзарәттә Казанның корбан чалу урыннары өчен җаваплы вәкилләр җыелды

17 нче июль көнне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең конференц-залында Казан шәһәрендә корбан чалу урыннары өчен җаваплы вәкилләр катнашында җыелыш уздырылды. Чарада Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, Казан шәһәре Башкарма комитетының Телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге җитәкчесе Илнур Шакиров, Казан шәһәренең Вахитов районы баш ветеринария табибы Илгиз Камалов, Россия Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең ТР буенча идарәсе ашау-эчү гигиенасы буенча күзәтү бүлеге баш белгече Алсу Хәсьянова, Россия Эчке Эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча җәмәгатьчелек тәртибен саклау бүлеге җитәкчесе урынбасары Ринат Йосыпов, шулай ук башкала-ның барлык имам-мөхтәсибләре һәм корбан чалу гамәле башкарылачак мәчетләрнең имамнары катнашты.

Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин Корбан чалу көннәре, тәртипләре, нисаб күләме хакында мәгълүмат бирде, шәһәр җирлегендә әлеге гамәлне башкару әдәбе һәм үзенчәлекләре турында сөйләде.

Казан шәһәренең Вахитов районы баш ветеринария табибы Илгиз Камалов сөйләп узганча, корбан чалу урыннарына китерелгән барлык малтуарларның да ветеринарлардан алынган рөхсәт язулары булуы шарт, документлары булмаган эшмәкәрләр, сатучылар, фермерларның хайваннары корбан чалу урыннарына якын китерелмәячәк. Ветеринарларның тагын бер җитди таләбе – корбан чалу урыннарында кан салу өчен савытлар булдыру.



Башкалада зур корбан чалу урыннарына Алабуганың «Сария Био-Индастрис Волга» ҖЧҖ заводы тарафыннан махсус контейнерлар урнаштырылачак һәм терлекчелекнең зыянлы продуктлары, алга таба эшкәртү өчен, оешманың шәхси транспорты белән Алабуга икътисадый зонасына алып кителәчәк. Корбан гаете көннәрендә әлеге контейнерларга хайваннарның биокалдыкларын җыеп барып утильләштерү иң кулай һәм экологик яктан куркынычсыз ысул булып тора. Шуңа күрә, «Сария Био-Индастрис Волга» заводы контейнерлары куелмаган урыннарда корбан чалучылар өчен дә үтенеч җиткерелде: биокалдыкларны ныклы пакетларга тутырып бәйләргә һәм «Сария Био-Индастрис Волга» заводы контейнерларына илтеп бушатырга кирәк булачак.

■ dum.rt

# Корбан чалу Аллаһыга якынайта

Улы Исмәгыйльне корбан итәргә алып барганда, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтан анын янына килеп вәсвәсә кылып: «Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач тизрәк», – дип әйтә. Сөекле әтиәнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга иялөшмәгән бала: «Мин Аллаһы әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли», – дип, мәлгунне ташлар атып куып җибәрә.

Ата белән ул Аллаһының боерыгына каршы килмиләр, итагать итәләр. Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте итеп Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешенең кисәр өчен кулындагы пычагы үтми. Корбан итәргә дип Җәбраил фәрештә җәннәттән сарык китерә.

Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһының киң кодрәтен күрәбез.

Ошбу бәйрәмгә карата берничә мәсьәләне карап китәсе килә. Корбан чалу кайсы хөкемгә керә? Һәм кешегә бу гамәл мәҗбүри булсын өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш соң? Байлыгы һәм мөмкинчелеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу вәҗиб гамәл санала. Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ яшендә булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде мөмкинчелеге булмаса, чалмаса да гөнаһ булмас. Шулай да бу изгелекле эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый, чөнки корбан чалганда хайванның беренче тамчы каны җиргә тамганчы ук суючының гөнаһлары кичерелә. Бу гамәлдә, башкалардагы кебек үк, ният мөһим әһәмияткә ия. Аллаһы Тәгалә Коръәннең түбәндәге аятендә болай дип әйтеп үтә: **«Сез чалган дөяләрнең итләре, каннары Аллаһыга ирешмәс, бәлки тәкъвалыгыгыз вә изге гамәлләрегез генә ирешер».**

«Хаҗ», 22:37

## Корбан ителәсе хайванның сыйфатлары

Тагын бер мәсьәлә: корбан ителәсе хайванның кимчелекләре булырга тиеш түгел. Дөрестән дә, әгәр дә хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндә:

1. Хайванның күзе начар күрсә;
2. Хайванның бер аягы чатанлап, ләкин бу аның йөрүенә комачау итмәсә;
3. Тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;
4. Колаклары тишелгән булу;
5. Берничә теше булмау;
6. Койрыгының яки колагының зур булмаган бер өлеше булмау.

Ләкин иң яхшысы хайванның бу кимчелекләрдән пакь булуы. Ә кайбер җитдирәк кимчелекләр аркасында хайваннар корбанга чалынырга лаек түгел. Алар түбәндә:

1. Бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булса;
2. Аксаклыгы берәр урынга барып җитәр өчен комачау итсә;
3. Бер яки ике колагы да тулысынча кисеп атылган булса;
4. Күпчелек тешләре булмаса;
5. Бер яки ике мөгезе төптән сынган булса;
6. Койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булса;
7. Имчәкләре булмаса;
8. Бик тә хәлсез хайван булса;
9. Тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;
10. Көтүдәге калган хайваннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булса;
11. Нәҗес (чиста булмаган ризык) белән тукланса.

## Корбанга кайсы хайваннар чалына?

Алар – сарык, кәҗә, сыер, үгез, дөя. Калган хайваннарны корбанга тотарга ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җенесеннән дә, ана җенесеннән дә була ала. Нигездә, сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр дә сарык ярты еллык, әмма көр һәм таза, бер еллык кебек булса, аны да ярый. Ә эре мөгезле хайваннар ике яшьлек, дөя биш яшьлек булырга тиеш. Эре мөгезле хайван белән дөя бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Ләкин бергәләп эре хайванны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһы ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә инде аралырыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул ителми.

## Корбан чалу рәвеше

Башта тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары газаплямыйча, сул ягына яткырырга һәм башын кыйблага борып куярга кирәк. Вак мөгезле хайванның арткы уң аягыннан кала өч аягы да бәйләнә. Чаласы кеше ниятен әйтә, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннан «Әл-Әнгам» сүрәсенең бер өлеше укыла: **«Әйт: «Дөреслектә, минем намазым, гыйбадәтем Аллаһыга, яшәвем дә, үлемем дә Галәмнәрнең Раббысы ихтыярында, Аңа тиңдәшләр юк».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:162-163




Моннан соң «бисмилләһи» дип хайван чалына һәм дога кылына.

Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Корбан чалган кеше пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһы аңа ни теләсә, шуны бирер», – дип әйткән.

## Чалынган корбанның ите ничек таратыла?

Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе – ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалучының гаиләсенә кала.

Корбан чалуның үз хикмәте һәм файдасы да бар икәнен онытмаска кирәк. Корбан чалу, беренчедән, Аллаһыга һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик Ул моның белән безнең Үзенә якынлык дәрәҗәсен тикшерә. Шулай ук корбан Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта. Мөселманнарның корбан чалуы – аларның Аллаһы юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә.

Ә файдасына килгәндә, кешенең гөнаһлары ярлыкана, ул Аллаһыга шөкер итеп, Аның алдында булган бурычын үти; чалынган хайван Кыямәт көнендә чалучыны Сират күпере аша алып чыга һәм аның котылуында сәбәпче була. Мескен, ятимнәрне сөендереп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

Күпләребез бу йоланы авылларына якыннары янына кайтып үти, ә менә андый мөмкинчелекләре булмаучыларга берәр урынга мөрәҗәгать итеп булмыймы дип ихтыяҗ... диючеләр дә бар? Моның өчен Казаныбызның махсус кайбер җирләрендә корбан чалу урыннары әзерләнгән.

## Корбан ите кемнәргә таратылырга тиеш?

Корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаҗ, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә. Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр итне кисәкләргә бүлеп тарата; икенчеләр, табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл санала. Һәм ничек эшләсәң дә дөрес була.

Кардәшләрем, шушы олуг бәйрәмебез белән тәбрик итәм. Аллаһы Тәгалә чалыначак корбаннарыбыздан риза булсын, барыбызга да һәрвакыт Аның рәхмәтен тоеп яшәүне насыйп итсен.

■ **Тимергали хәзрәт Юлдашев, «Саләх» мәчете имам-хатыйбы**

# Гайбәт сөйләү – кеше яманлау

## Имеш-мимешләрдән ерак булыйк!



Динебез буенча, мөселманнар дуслык, тынычлык, өлфәт вә мәхәббәт эчендә яшәргә тиеш. Кешеләр арасындагы дуслык, самимият вә кардәшлек хисләрен бетереп, капма-каршы булган кинә (нәфрәт) вә дошманлык китереп чыгара торган начар нәрсәләрнең берсе – гайбәттер. Гайбәттән, сүз йөртүдән, кешеләрне рәнҗетә торган ямьсез вә начар сүзләрдән тартынырга кирәк, чөнки болар барысы да Ислам динендә харамдыр.

Беркөнне Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләреннән болай дип сораган:«Гайбәт нәрсә ул, беләсезме?» Сәхабәләр: «Аллаһы вә Аның Илчесе яхшырак белер», – дигәннәр. Шулвакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Дин кардәшенең хушына килмәгән сүзләрне аның артында (ягъни ул ишетмәгәндә) сөйләүдер», – дигән. Пәйгамбәребезнең сәхабәләре: «Әгәр кардәшләребезне яманлавыбыз дөрес булса, сөйләргә ярыймы?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Әгәр сөйләгән сүзләрең дөрес булса, гайбәт сөйләгән булырсың. Сөйләгән сүзләрең дөреслеккә туры килмәсә, яла яккан (бөһтан) булырсың», – дип кисәткән.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә гайбәт сөйләүне кеше ите ашауга охшаткан вә кешеләрне гайбәт сөйләүдән катгый рәвештә тыйган.

**«Әй, мөэминнәр, занның (уйдырмаларның, имеш-мимешләрнең) күбесеннән сакланыгыз, чөнки занның кайберләре гөнаһтыр. Башкаларның гаепләрен тикшермәгез. Бер-берегез турында гайбәт сөйләп йөрмәгез. Сезнең берәрегез вафат булган кардәшенең итен ашарга яратырмы? Менә җирәндегез. Алай булгач, Аллаһыдан куркыгыз».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:12

## Сөйләүчегә дә, тыңлаучыга да

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам гайбәт сөйләүчеләрне яратмаган. Әгәр бер кеше аның янында гайбәт сөйләргә тотынса, гайбәтнең харам вә гөнаһ булганын хәтерләтә торган булган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам гайбәтне тыңларга да рөхсәт итмәгән. Бер хәдисендә ул болай дигән: «Гайбәт сөйләүче белән гайбәтне тыңлаучының гөнаһлары уртактыр».

Гайбәт сөйләүчеләр – начар бер хасталыкка дучар булган кешеләрдер. Безнең яныбызда башкалар хакында гайбәт сөйләп торган кеше башкалар янында безнең хакта да ямьсез сүзләр сөйләргә һич тартынмас.

Мөселман булган кеше башкаларның гаебен эзләп, ул турыда анда-монда сөйләп йөрмәс. Яхшы кеше мөселман кардәшенең хата вә гаепләрен сер итеп сакларга тырышыр, чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Кем дә кем бер мөселман кардәшенә ярдәм итсә, Аллаһы да ул кешегә ярдәм итәр. Кем дә кем бер мөселман кардәшенең кайгысын бетерсә, Аллаһы Тәгалә дә Кыямәт көнендә аның кайгыларының берсен бетерер. Кем дә кем бер мөселман кардәшенең гаебен белдертмәсә, Аллаһы да Ахирәттә аның гаебен белдертмәс». Кем дә булса башкаларның гаепләрен тикшергәнче, беренче чиратта үзендә булган кимчелекләрне бетерергә, үзен яхшы кеше итеп тәрбияләргә тырышсын.

Гайбәтнең дөньяви тормышыбызда һәркем өчен зыяны күп булган кебек, аның Ахирәт өчен дә зарары бар: Ахирәттә гайбәт изгелекләр вә гыйбадәтләрдән казанган савапларның югалуына сәбәп булыр.

## Дәшми калу да хикмәт



Мөселман булган кеше бары тик яхшы вә файдалы сүзләр генә сөйләр. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу турыда болай дигән: «Аллаһыга вә Ахирәт көненә ышанган кеше хәерле вә файдалы гына сүз сөйләсен яисә дәшмәсен».

Уйлап карыйк әле, безнең башыбызда бер көн эчендә генә дә шушындый төр фикерләр ничә тапкыр килеп китә икән? Ә шушы “бик мөһим” мәгълүматны калганнарга ничә тапкыр җиткерәбез без?

Үзебезгә кайтып калганда, аклану эзли башлыйбыз, ә Бөек Кодрәт иясе Аллаһы Тәгаләнең калган мәхлүкларына карата эчкерсез булырга онытабыз. Әйдәгез, бу күңел авыруыннан бергәләп котылыйк. Берәр кешене гаепләргә теләгән саен, аның өчен Аллаһы Тәгаләгә яхшы дога кылыйк. Мисалга, берәр кыска итәкле кызны күргәннән соң, эчебездән: “Аллаһым, мине иманлы итеп кылганың өчен Сиңа мең шөкер әйтәмен. Бу колыңны да Үзеңә итагать итүчеләрдән кылсаң иде”, – дип дога кылырга кирәк.

Шулай да, кем дә булса мөселман кардәшенә яхшылык теләп, ул үзе янда булганда ихлас вә самимият белән аны тәнкыйть итсә, ул гайбәт булып саналмас, чөнки мөселман дин кардәшенә карата булган вазифасын да үтәргә тиеш. Бу эш гайбәт булып түгел, хаклыкны вә хакыйкатьне тәүсыя итү (теләү) булып саналыр.

## Башта гаеп табабыз, аннары шуны сөйлибез



Җәгъфәр бине Мөхәммәднең сүзләрен исебездән чыгармыйк: “Үзегезнең дин кардәшегез турында берәр начар сүз ишетсәгез, аның бу эшенә 70 төрле аклану табыгыз. Әгәр тапмасагыз, бу акланунык аның үзендә барлыгына үз-үзегезне ышандырыгыз”.

Аллаһы Тәгалә “Нур” сүрәсендә болай дип әйтә:

**“Ни өчен ул хәбәрне ишеткәч күңелегездән яхшы уй уйламадыгыз, мөэмин ирләр вә мөэминә хатыннар үзләре хакында яхшылыкны уйлаганнары кебек, ни өчен бу хәбәрне дә ачык ялган дип әйтмәдегез? Ул хәбәрне телегез белән каршы аласыз, аннары авызыгыз белән сөйлисез, ләкин ул хәбәр хакында белемегез, дәлилегез юк, янә сез ул җиңел эш, анда гөнаһ юк дип уйлыйсыз, әмма Аллаһы хозурында ул зур эштер, газабы каты булыр.”**

«Нур», 24:12-15

Кешедән гаеп табу – җиңел эш. Бүтән бер кешенең бер генә хатасын кешегә җиткерсәң, бу кешегә карата хөрмәт тә бетүе бар. Һәм бигрәк тә, ул кешенең изге гамәлләрен күрмичә, бары начарлык кына күтәп торачаклар.

Шуңа да телебезне зикер белән мәшгуль кылыйк! Аллаһы Тәгаләне искә алган кешене Аллаһы Тәгалә Үзе дә искә ала дип әйтелә хәдисләрдә.

■ “Хозур” редакциясе

# Имам Мәлик рахимәһуллаһи




Имам Мәлик рахимәһуллаһи күренекле мөхәддис һәм мөҗтәһид булу белән генә түгел, ә үзенең тәкъвалыгы, дөреслеге һәм басынкы холкы белән танылган булган.

## Тумышы

Әбү Габдулла Мәлик бине Әнәс Әл-Әсхәби күбрәк имам Мәлик исеме белән билгеле. Имам Мәлик табигыйннәр чорында, якынча 713 нче елда Мәдинәгә якын булган Зи-Мәрвә дип аталган районда туган.

Нәсел-нәсәбе сәүдә белән шөгыльләнгән. Әтисе уклар ясау остасы булган.

## Гыйлем туплавы

Имам Мәлик кече яшьтән үк гыйлемгә тартылган. Ул яшәгән йорт төп гыйлем үзәге булган. Иң беренче Коръән гыйлемнәрен абзасы Әбү Сөхәйл Нәфидән алган. Бабасы хәдисләр белүче буларак танылган.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи гыйлемне табигыйннәрдән, шулай ук факиһлардан һәм мөхәддисләрдән алган. Коръәнне Нәфигъ Мәүла бине Гомәрдән һәм Габдрахманнан өйрәнгән. Унөч ел дәвамында Габдрахман бине Хурмузның түгәрәгенә йөреп, аннан һәм аның укучыларыннан гыйлем алган.

Унҗиде яшенә үк инде гыйлемгә тартылуы, фикер сәләтенең нык үсеше һәм дә тырышлыгы нәтиҗәсендә имам Мәлик рахимәһуллаһи югары ислам гыйлемен туплый. Нәкъ шушы вакытта остазлары һәм галимнәрнең рөхсәте белән имам Мәлик рахимәһуллаһи укыта башлый һәм фәтвалар бирә.

## Имам Мәликнең укучылары

Имам Мәлик рахимәһуллаһи бик күп мөселманнарга гыйлем биргән, аларның саны 1300гә якын булган. Алар арасында имам Мәлик рахимәһуллаһиның үзенең мөгаллимнәре, хезмәттәшләре һәм яшь галимнәр дә бар. Имам Мәлик рахимәһуллаһида Ибне Шиһаб Зуһри, Яхъя бине Сәед Әл-Кари, Йәзид бине Габдулла, Суфиян Сәүри, Габдрахман бине Мәһди, Габдулла бине Мөбарәк, имам Шәфигый, Ибне Касыйм һәм башкалар гыйлем алганнар.

## Имам Мәлик рахимәһуллаһиның холкы

Имам Мәлик рахимәһуллаһи югары әхлакый сыйфатларга ия булган, аралашканда үзен гади тоткан.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи беркайчан да тәһарәтсез килеш хәдис сөйләмәгән. Хәдис сөйләр алдыннан ул иң элек тәһарәт алган, аннан ике рәкәгать намаз укыган. Шуннан соң утырып, сакалын тараган, ислемайлар сөрткән. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә шул рәвешле хөрмәтен күрсәткән. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең исеме телгә алынганда, ул хәтта йөзе белән үзгәрә торган булган.

Аның хәтер дә бик әйбәт булган. Мактанып йөрмәгән, тыйнак булган. Белмәгән әйберен белмим дип әйтүдән оялмаган.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи бигрәк тә Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләре һәм сәхабәләренең фәтвалары белән кызыксынган. Мәдинәдә яшәп, ул күп кенә сәхабәләрнең берничә буыны белән аралашкан, төрле фәлсәфә мәктәпләренең хезмәтләре белән танышкан. Тора-бара Мәдинәдә абруйлы факиһка әйләнгән.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи фәтвалар чыгарганда бик игътибарлы һәм сак булган. Җитмеш галим фәтва чыгаруда аңа шаһитлык белдергәннән соң гына ул фәтвалар чыгара башлаган. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үтәүдә дә бик таләпчәнлек күрсәткән. Мәдинәдә аңа "Һиҗрәт йорты имамы" дигән кушамат биргәннәр.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи чорында бик күп агымнар барлыкка килгән, ләкин ул аларның берсенә дә якын килмәгән. Дингә кертелгән яңалыкларга (бидгать гамәлләргә) нәфрәт белән караган. Тулысынча Коръәнгә һәм сөннәткә нигезләнгән гакыйдәгә ияргән.

## "Әл-Мүвәттә"

Мәлик бине Әнәс Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышына бәйле вакыйгаларны туплау, аларның тапшыручыларын (равилар) ачыклау һәм дөреслеген билгеләүгә аеруча игътибар биргән. Ул аларны туплап "Китап әл-Мүвәттә" дип аталган хәдисләр җыентыгы әзерләгән. Бу хезмәтне язар өчен ул кырык ел сарыф иткән. Әлеге китапта ул беренчеләрдән булып хәдисләр туплаган һәм аларны системалаштырган. Бу җыентыкка бик нык тикшергән, дөрес хәдисләрне генә сайлап алып урнаштырган, хәтта бабасы аша әтисеннән яки абзасыннан ишетелгән хәдисләрне дә кертмәгән. Бохариның "Сахыйх" хәдисләр җыентыгы язылганчы Мөхәммәд бине Идрис Әш-Шәфигый имам Мәликнең "Мүвәттәсе" хакында мондый сүзләр әйткән: "Мәликнең китабына караганда Коръәнгә якын булган дөньяда бернинди китап та булмады".

Һарун Әр-Рәшид хәлифә имам Мәлик рахимәһуллаһиның бу күренекле хәдисләр җыентыгын Кәгъбәгә куеп, барлык мөселманнарга да хокукый мәсьәләләрдә имам Мәлик рахимәһуллаһига ияргә дигән фикер белән чыга. Имам Мәлик рахимәһуллаһи бу тәкъдимне кире кага һәм болай дип әйтә: "Моннан баш тартыгыз, чөнки Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре үзләре дә икенче дәрәҗәдәге мәсьәләләр буенча төрле фикерләрдә торганнар. Гади халык инде ул фикерләргә ияргән. Барысы да хак юлда табыла".

## Имам Мәлик рахимәһуллаһиның укыту ысулы

Имам Мәлик рахимәһуллаһи үзенең язып баручысы Хәбибне "Мүвәттә"дән хәдисләр укып барырга билгели торган булган. Имамның укучылары һәм башкалар имам Мәлик рахимәһуллаһидан курыкканга һәм аңа карата хөрмәт йөзеннән игътибар белән тып-тын гына Хәбибне тыңлаганнар. Укучыларның берсе дә хәдисләр җыентыгына күз төшерергә һәм дә сорау бирергә җөрьәт итмәгән. Хәбиб хәдис укыганда ялгышса, имам Мәлик рахимәһуллаһи шул вакытта ук аның хатасын дөресли торган булган. Кайвакытларда имам Мәлик рахимәһуллаһи үзе дә "Мүвәттә"дән хәдисләр укыган.

Имам Мәлик рахимәһуллаһиның кызы Фатыйма "Мүвәттә"не яттан белгән. Дәресләр вакытында, гадәттә ул ишек артында басып торган. Әгәр дә хәдис укучы ялгышса, ул ишеккә кага торган булган. Имам моны аңлап, хатаны төзәткән.

Имам Мәлик рахимәһуллаһиның Яхъя исемле улы күренекле галимгә әйләнгән. Ул Мисырга барып хәдис буенча дәресләр биргән.

## Имамның вафаты

Гомеренең соңгы елларында имам Мәлик рахимәһуллаһи ялгызлыкта калырга тырышкан, хәтта җомга намазларына да бармаган. Имам болай әйтә торган булган: "Һәркем дә ачыктан-ачык үз хәленең сәбәбен аңлата алмый".

Икенче бер риваятьтә килгәнчә, имам Мәлик рахимәһуллаһи үзенең сидек куыгының көчсезлеге хакында әйткән. Мондый хәлендә Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчетенә йөрүне ул хөрмәт күрсәтмәү кебек санаган. Имам шулай ук үз авыруын ачыктан-ачык әйтеп йөрергә теләмәгән, моны Аллаһы Тәгаләнең биргәненә зарлануга тиң дип санаган.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи рабигыль-әүвәл аеның 14 нче көнендә, 795 нче елда вафат була. Җеназа намазын Мәдинә әмире Габделгазиз бине Мөхәммәд укый. Үлеме алдыннан имам Мәлик рахимәһуллаһи шәһадәт сүзләрен һәм шуннан соң Коръәннең түбәндәге аятен әйтә:

**«Моннан алда да, моннан соң да эшләр (бөтен карарлар һәм вәкаләтләр) Аллаһыныкы гына».**

«Рум», 30:4

Имам Мәлик рахимәһуллаһи Җәннәт Әл-Бакый зиратына күмелә.

■ **Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде**

# Гарәфә көне турында



Зөлхиҗҗәнең беренче ун көнлегендә иң хәерлесе, иң яхшысы, әлбәттә инде – Гарәфә көне. Ул Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көненә туры килә. Ул чын мәгънәсендә ел дәвамында иң яхшы көннәрнең берсе булып тора. Үзенең «Сахих» хәдисләр җыентыгында Ибне Хиббан Җәбирнең мондый хәдисен китергән: «Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәбиргә: «Иң яхшы көн – ул Гарәфә көне», – дип әйткән».

Гарәфә көнен тагын икенче төрле «тану көне» дип тә йөртәләр. Бу Ибраһим галәйһиссәламнең нәзере хәтеренә килеп, төшен аңлаган көнедер.

Имам Мөслимнең «Сахих» хәдисләр җыентыгында мондый тарих китерелә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гайшә радыяллаһу ганһә анабызга Гарәфә көненең фазыйләтләре хакында: «Ут газабыннан иң күп кеше Гарәфә көнендә котылачак», – дигән хәбәр бирде.

Гарәфә көнендә иртәнге намаздан башлап, Зөлхиҗҗә аеның 13 нче көнендәге икенде намазына кадәр (икенде намазы кереп) егерме өч фарыз намазның һәркайсыннан соң сәлам биргәч, Аллаһы Тәгаләне олылап, Аны данлап, бер мәртәбә тәкбир әйтергә тиеш булабыз. Бу – тәшрикъ көннәре дип атала. Имам вә җәмәгать белән намаз укыганда тәкбирнең вәҗиб булуының мәгънәсе – адәм балалары Җир йөзенә яшәр өчен яратылды; адәм каны коелмасын, хайван каны гына коелсын, дип сөенечтән тәкъбир әйтүдәдер.

## Бу көннәрне уразалы үткәрик

Гарәфә көне турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Гарәфә көнне тоткан ураза ике еллык гөнаһларны, Гашура көнне тоткан (Мөхәррәм аеның унынчы көне) ураза бер еллык гөнаһларны сөртә», – дигән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер хәдисендә: «Гарәфә көнендә тотылган ураза ике ел буе кылынган гөнаһларны ярлыкарга җитәрлек савап китерәчәк», – дип әйткән. Шуның өчен мөселман кардәшләребез Зөлхиҗҗә аеның беренче сигез көнендәге изгелекләренә өстәп, тугызынчы Гарәфә көнен тагын бер гыйбадәт – ураза гыйбадәте белән дә үткәрәләр. Кемдер исә беренче сигез көнен дә һәм Гарәфә көнен дә ураза тотып үткәрә.

## Ни өчен бу көн Гарәфә көне дип атала?

Бу көнне хаҗда булган кешеләр өйләдән алып, кояш батканчыга кадәр Гарәфә тавы үзәнендә догалар укып, теләкләр теләп торалар. Өч миллионнан артык кара, ак, сары, кызыл тәнле бөтендөнья мөселман халкы һәрберсе үз телендә елый-елый, Раббыларына мөрәҗәгать итәләр, дога кылалар. Бу күренеш мөселман өммәтенең бер тән, бер җан, бер сулыш булып яшәвен күрсәтә. Гарәфә тавында басып торган хаҗилар – мөселман өммәтенең бердәмлеге символы кебек. Төрле җирләрдән җыелган булуына, төрле телдә сөйләшүенә, баймы-фәкыйрьме булуына да карамастан, алар барысы да Аллаһы Тәгалә юлындагы кардәшләр.

Алар бер тавыштан түбәндәге доганы кабатлыйлар:

**Ләббәйкә Аллаһуммә ләббәйк, ләббәйкә ләә шәриикә ләкә ләббәйк. Иннәл-хәмде, вәлнигъмәтә ләкә вәл мүлк, ләә шәриикә ләк.**

Аның мәгънәсе: «Йә Аллаһы, менә мин Синең каршыңда! Менә мин синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк! Барча мактау Сиңа гына, барлык нигъмәт һәм хөкем Синең кулыңда гына! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк!»

Әлеге сүзләрне бертавыштан кабатлаган кардәшләребезне күрү бик сөенечле вакыйга. Гарәфәт тавында тору – аерым бер могҗизаи халәт ул. Биредә хаҗиларның йөрәкләре шатлык белән тула, күзләре ирексездән ихлас яшьләнә. Нәкъ менә биредә барлык хаҗиларның күңеленә Мәккә җирләренә карата чиксез мәхәббәт хисе кереп оялый. Гарәфәттән соң Хаҗ урыннарын калдырып китсә дә килми башлый, ә киткәннән соң, бу урыннарга кабат кайтасы килә, ди хаҗда булып кайтучылар.

Күп кешеләр ошбу мизгелләрдән соң үз илләренә гыйбрәтләнеп, тәэсирләнеп кайталар һәм кылган догаларының үтәлә башлауларын күреп, хәйран калалар. Шуңа күрә, Гарәфә көнен хаҗның иң әһәмиятле ноктасы, дип тә әйтергә була, чөнки пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Хаҗ ул – Гарәфә», – дип искәрткән.

Ә хаҗда булмаган барлык мөселманнар ошбу бөек көнне, югарыда искәрткән хәдискә таянып, уразада үткәрәләр. Һәм, ин шә Аллаһ, Аллаһының рәхмәте белән ике еллык гөнаһларын бетерергә тырышалар. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһының рәхмәте киң, ә безнең гөнаһларыбыз юк түгел. Ошбу изгелек кылу, гөнаһлардан пакьләнү форсатларын кулдан ычкындырмасак иде.

■ **ТҖ МДН дәгъват бүлеге**




# «Әт-Тәшрикъ» тәкбире

Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Корбан бәйрәменең дүртенче көнендәге ахшам намазына тикле (ягъни быел бу даталар 10 нчы августның иртәнге намазыннан алып, 14 нче августның ахшам намазы кергәнче), һәрбер фарыз намаздан соң (барлыгы 23 намаз) тәшрикъ тәкбире укыла:

اللّٰهُ اَكْبَرُ اللّٰهُ اَكْبَرُ لا إِلٰهَ إِلَّا اللّٰهُ اللّٰهُ

اَكْبَرُ اللّٰهُ اَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләәллаahу. Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә лилләәһил хәмде.

*Тәрҗемәсе:*

«Аллаһы Бөек, Аллаһы Бөек, Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы Бөек, Аллаһы Бөек, бар мактаулар Аллаһыга».

Әлеге тәкбирне әйтү, бөтен җәмәгать өчен дә, аерым һәр кеше өчен дә вәҗиб булып санала. Ирләр тавыш белән әйтәләр, ә хатыннар эчтән генә кабатлыйлар. Вәҗиб булган витр намазыннан соң тәшрикъ тәкбире әйтелми.

Кемнеңдер бу көннәрдә кылынмый калган намаз бурычы булса, һәм ул калдырган намазларын тәшрикъ көннәрендә каза итеп укырга җыенса, аларны укыгач, тәшрикъ тәкбирен әйтергә тиеш. Каза намазларын бу көннәр узгач укыса, тәшрикъ тәкбире әйтелми.

■ **“Ислам дине нигезләре” китабыннан**

# Теләкләр һәм тәсбихләр

Кешегә яхшы теләк теләү гадәте элеккегедән калган бик күркәм күренеш. Авылыбызда берәр кешенең ни дә булса эшләгәнен күрсәк, еркатан ук: “Аллаһы куәт бирсен!” – дип кычкыра идек. Үзең дә шулай дигәндә, ихлас күңелдән рәхмәт әйтәсең. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер хәдисендә болай дип әйтелә: “Сезгә эшләнгән яхшылыкка һәм күрсәтелгән ярдәмгә каршы шулай ук җавап кайтарыгыз. Әгәр алай эшли алмасагыз, алар өчен дога кылыгыз”. Аллаһы Тәгаләдән берәр кешегә куәт бирүен сорау – ул дога. Шуңа да, ишеткән кеше “әәмин” дип, аның кабул булуын сорый. Пәйгамбәребезнең югарыдагы хәдисендә: “Шулай ук җавап кайтарыгыз”, – диелә, ягъни яхшылыкка бары тик яхшылык белән җавап бирелә. Ә иң яхшы гамәлләрнең берсе – Пәйгамбәребез сөннәте буенча җавап кайтару. Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйткән: “Яхшылык эшләгән кешегә карата берәрегез “Җәзәкәл-лаһу хайран” дип әйтсә, бу иң югары дәрәҗәдәге рәхмәт әйтү булыр”.




**“Җәзәкәл-лаһу хайран”** – гарәп теленнән “Аллаһы Тәгалә сезгә хәерлелек бирсен”, яки “Аллаһы сине яхшылык белән бүләкләсен” дип тәрҗемә кылына.

Гомәр радыяллаһу ганһе бу гыйбарә турында: “Мөселман кардәшеңә “Җәзәкәл-лаһу хайран” дигән өчен нәрсәләр әзерләнгәнен белсәгез, аны бер-берегезгә ешрак әйтер идегез”, – дип әйтә.

Бу сүзне әйткән кешегә җавап итеп “вә ииййәкә”, ягъни “сиңа да” дип әйтү каралган.




Кешегә фатиха сораганда “**бәрәкәллаһу фиикә”** дип әйтелә. Татар теленә ул “Аллаһы Тәгалә сиңа фатиха бирсен” яки Аллаһы Тәгалә сиңа бәрәкәт бирсен” дип тәрҗемә кылына. Бу сүзне дә рәхмәт әйткәндә дә, кешегә күз тимәсен өчен дә әйтергә була, чөнки бәрәкәт – ул “һәрвакыт була торган”, “беркайчан да кимеми торган” дигәнне аңлата. Бу гыйбарә турында тулырак мәгълүматны газетабызның узган елдагы декабрь санынынан укып белә аласыз. Бу сүзләрне әйткән кешегә “вә фиикүм бәрәкәллаһ” дип җавап кайтарылыр.




Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**“Ул чыдамлы мөэминнәргә берәр бәла килсә: “Һичшиксез, без – Аллаһыныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!”** – дип әйтәләр.

“Бәкара / Сыер”, 2:156

Бу аятьтә **“Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раажигуун”** гыйбарәсе кулланылган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләре аны берәр мәшәкать, авырлык килсә дә әйтә торган булганнар. Бүгенге көндә аны берәр кеше вафат булгач кына әйтәләр дип уйлаучылар да бар. Әмма бер очракны исегезгә төшерәсе килә: Бервакыт юлдан барганда Гомәр радыяллаһу ганһенең аяк киеменең бавы сүтелә. Ул иелеп аны бәйли башлый һәм: “Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раажигуун”, – дип әйтә. Янында торган сәхабәләр: “Йә, Гомәр, бу сүзне берәр мусыйбә (авырлык) килгәч кенә әйтмиләрмени?” – дип сорыйлар. Шулвакыт Гомәр радыяллаһу ганһе: “Мөселманга ошамаган (аз булса да авырлык китерә торган) теләсә нинди вакыйга мусыйбә (сынау, авырлык) була”, – дип җавап кайтара.

Әлеге гыйбарә татар теленә “Һичшиксез, без – Аллаһыныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз” дип тәрҗемә кылына. Һәм, чыннан да, нинди генә авырлык килмәсен, без барыбыз да Аллаһыныкылар, шуңа күрә Аңа гына тәвәккәл кылабыз да.

**“Аллаһуммә инни әгуүзү бикә минәл хүбси вәл хәбәәис”**, ягъни “Аллаһым, мин ир-ат һәм хатын-кыз җенесле шәйтаннардан Сиңа гына сыенам”. Бу сүзләрне ешрак бәдрәфкә кергәндә әйтәләр. Әмма шәйтаннардан һәм аларның явызлыгыннан сыенарга теләгән саен йә бу гыйбарәне,




йә “Әгүҗү”не әйтергә дә була.

Бу сүзләр бәдрәфкә кергәнче әйтелсә, аннан чыккач “гуфранәкә” дип әйтелер. Ул “(Аллаһы), Синнән гафу сорыйм” дип тәрҗемә кылына.

**“Әстәгъфируллаһ”** – гарәп теленнән “Аллаһы Тәгаләдән гафу итүен сорыйм” дип тәрҗемә кылына. Пәйгамбәребезнең көненә 70тән артык (шулай ук 100дән артык) Аллаһы Тәгаләдән гафу сораганы билгеле. Шуңа күрә бу сүзне бик еш кабатларга кирәк. Шулай ук “раббигъ-фирлии” дигән гыйбарәне дә куллансаң була. Ул “Раббым, мине кичер” дип тәрҗемә кылына.




Гомумән, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә торган кыска гыйбарәләр бик күп. Алар турында язмаларны алдагы саннарда дәвам итәрбез, ин шә Аллаһ.

Бүгенге көндә еш кына түбәндәге очракны күзәтергә була: әгәр кеше берәр вакыйгага тап булса, ул тизрәк “абау”, “булмас ла” дип куя. Шушы сүзләр урынына кулланылган “мә шә Аллаһ”, ягъни «Аллаһы теләгән әйбер булды» кебек гыйбарәләр сөйләмебезне күркәмрәк кылыр һәм әйткән өчен әҗер-савапка да ирештерер иде. Сөйләмебезне күркәм һәм мәгънәле сүзләр белән генә бизик.

■ **Сәхифәне Гәбделхәким Фәсхиев әзерләде**

## Дүшәмбе
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
8:25 Рисалә. Г. Насыйри
8:35 Бер хәдис – бер җавап
8:55 Мәслихәт
9:15 Намазга өйрәник
9:35 Гаилә дәресләре
10:00 Хикмәтле хикәяләр
10:15 Балам-багалмам
10:35 Әкиятләр иле
10:45 Барбаросса (Мультфильм)
11:05 Хәдис дәресләре
11:25 Мультфильм
11:35 Җан авазы
11:45 Мукабалә (Коръән)
12:00 Азан
12:05 Азбука ислама
12:25 Мультфильм (рус телендә)
12:40 Ислам без стереотипов
12:55 Есть хадис – есть ответ
13:15 Мим
13:25 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:35 Мусульмане, которыми гордится Россия
14:05 Мукабаля (Чтение Корана)
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
17:25 Рисалә. Габделкаюм Насыйри
17:35 Бер хәдис – бер җавап
17:55 Мәслихәт
18:15 Намазга өйрәник
18:35 Гаилә дәресләре
19:00 Хикмәтле хикәяләр
19:15 Балам-багалмам
19:35 Әкиятләр иле
19:45 Барбаросса (Мультфильм)
20:05 Хәдис дәресләре
20:25 Мультфильм
20:35 Җан авазы
20:45 Мукабалә (Коръән)
21:00 Мастерская мусульманки
21:40 Мультфильм (рус телендә)
21:55 Ислам без стереотипов
22:10 Есть хадис – есть ответ
22:30 Мим
22:40 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:50 Мусульмане, которыми гордится Россия
23:20 Художественный фильм

## Сишәмбе
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
8:25 Рисалә. Г. Насыйри
8:35 Бер хәдис – бер җавап
8:55 Мәслихәт
9:15 Әлифба сабаклары
9:25 Гаилә дәресләре
9:50 Хикмәтле хикәяләр
10:05 Бәрәкәтле гаилә
10:50 Балам-багалмам
11:10 1001 хәзинә
11:20 Барбаросса (Мультфильм)
11:40 Мукабалә (Коръән)
12:00 Азан
12:05 Почитайка
12:15 Мультфильм (рус телендә)
12:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:40 Ислам без стереотипов
12:55 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:25 40 хадисов – 40 толкований
14:00 Мим
14:10 Мультфильм (рус телендә)
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
17:25 Рисалә. Каюм Насыйри
17:35 Бер хәдис – бер җавап
17:55 Мәслихәт
18:15 Әлифба сабаклары
18:25 Гаилә дәресләре
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:05 Бәрәкәтле гаилә
19:50 Балам-багалмам
20:10 1001 хәзинә
20:20 Барбаросса (Мультфильм)
20:40 Мультфильм
20:50 Мукабалә (Коръән)
21:05 Мастерская мусульманки
21:45 Мультфильм (рус телендә)
22:00 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:10 Ислам без стереотипов
22:25 Мусульмане, которыми гордиться Россия
22:55 40 хадисов – 40 толкований
23:30 Мим
23:40 Художественный фильм

## Чәршәмбе
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
8:25 Бер хәдис – бер җавап
8:45 Мәслихәт
9:05 Җан авазы
9:15 Намазга өйрәник
9:40 Гаилә дәресләре
10:05 Хикмәтле хикәяләр
10:20 Барбаросса (Мультфильм)
10:40 Хәдис дәресләре
11:00 Шифа
11:35 Мукабалә (Коръән)
12:00 Азан
12:05 Азбука ислама
12:25 Мультфильм (рус телендә)
12:40 Ислам без стереотипов
12:55 Есть хадис – есть ответ
13:15 Мим
13:25 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:35 Мусульмане, которыми гордится Россия
14:05 Мукабаля (Чтение Корана)
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
17:25 Бер хәдис – бер җавап
17:45 Мәслихәт
18:05 Җан авазы
18:15 Намазга өйрәник
18:40 Гаилә дәресләре
19:05 Хикмәтле хикәяләр
19:20 Барбаросса (Мультфильм)
19:40 Хәдис дәресләре
20:00 Шифа
20:35 Мультфильм
20:45 Мукабалә (Коръән)
21:00 Мастерская мусульманки
21:40 Мультфильм (рус телендә)
21:55 Маленькие взрослые
22:00 Ислам без стереотипов
22:15 Есть хадис – есть ответ
22:35 Мим
22:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:55 Мусульмане, которыми гордится Россия
23:25 Художественный фильм

## Пәнҗешәмбе
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
8:25 Рисалә. Габделкаюм Насыйри
8:35 Бер хәдис – бер җавап
8:55 Мәслихәт
9:15 Җан авазы
9:25 Әлифба сабаклары
9:35 Гаилә дәресләре
10:00 Хикмәтле хикәяләр
10:15 Хәдис дәресләре
10:35 Бәрәкәтле гаилә
11:20 Барбаросса (Мультфильм)
11:40 Мукабалә (Коръән)
12:00 Азан
12:05 Почитайка
12:15 Мультфильм (рус телендә)
12:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:40 Ислам без стереотипов
12:55 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:25 40 хадисов – 40 толкований
14:00 Мим
14:10 Мультфильм (на русском)
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
17:25 Рисалә. Каюм Насыйри
17:35 Бер хәдис – бер җавап
17:55 Мәслихәт
18:15 Җан авазы
18:25 Әлифба сабаклары
18:35 Гаилә дәресләре
19:00 Хикмәтле хикәяләр
19:15 Хәдис дәресләре
19:35 Бәрәкәтле гаилә
20:20 Барбаросса (Мультфильм)
20:40 Мультфильм
21:00 Мастерская мусульманки
21:40 Мультфильм (рус телендә)
21:55 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:05 Мусульмане, которыми гордится Россия
22:35 40 хадисов – 40 толкований
23:10 Мим
23:20 Художественный фильм

## Җомга
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
8:25 Рисалә. Габделкаюм Насыйри
8:35 Бер хәдис – бер җавап
8:55 Мәслихәт
9:15 Җан авазы
9:25 Намазга өйрәник
9:50 Гаилә дәресләре
10:15 Хәдис дәресләре
10:35 Хикмәтле хикәяләр
10:50 Барбаросса (Мультфильм)
11:10 Минбар (Җомга вәгазьләре)
11:40 Мукабалә (Коръән)
12:00 Азан
12:05 Почитайка
12:15 Мультфильм (рус телендә)
12:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:40 Ислам без стереотипов 13 (6)
12:55 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:25 40 хадисов – 40 толкований
14:00 Мим
14:10 Мультфильм (на русском)
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәфсир Тимергали хәзрәт Юлдашев
17:25 Рисалә. Габделкаюм Насыйри
17:35 Бер хәдис – бер җавап
17:55 Мәслихәт
18:15 Җан авазы
18:25 Намазга өйрәник
18:50 Гаилә дәресләре
19:15 Хәдис дәресләре
19:35 Хикмәтле хикәяләр
19:50 Барбаросса (Мультфильм)
20:10 Минбар (Җомга вәгазьләре)
20:40 Мукабалә (Коръән)
21:00 Мастерская мусульманки
21:40 Мультфильм (рус телендә)
21:55 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:05 Мусульмане, которыми гордится Россия
22:35 40 хадисов – 40 толкований
23:10 Мим
23:20 Художественный фильм

## Шимбә
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Хәерле сәгатьтә
9:00 Барбаросса (Мультфильм)
9:20 Барбаросса (Мультфильм)
9:40 Барбаросса (Мультфильм)
10:00 Мәслихәт
10:20 Мәслихәт
10:40 Мәслихәт
11:00 Әлифба сабаклары
11:10 Әлифба сабаклары
11:20 Хикмәтле хикәяләр
11:35 Хикмәтле хикәяләр
11:50 Җан авазы
12:00 Азан
12:05 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:35 Мультфильм (рус телендә)
12:50 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:20 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:50 Мим
14:20 Художественный фильм
16:00 Гаилә дәресләре
16:25 Гаилә дәресләре
16:50 Гаилә дәресләре
17:15 Бәрәкәтле гаилә
18:00 Минбар (Җомга вәгазьләре)
18:30 Хәдис дәресләре
18:50 Хәдис дәресләре
19:10 Хәдис дәресләре
19:30 Балам-багалмам
19:50 1001 хәзинә
20:00 Хәләл-info
20:15 Шифа
20:50 Мультфильм
21:00 Почитайка
21:10 Мастерская мусульманки
21:50 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:20 Мим
22:50 Мусульмане, которыми гордится Россия
23:20 Художественный фильм

## Якшәмбе
7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Хәерле сәгатьтә
9:00 Хәерле сәгатьтә
10:00 Барбаросса (Мультфильм)
10:20 Барбаросса (Мультфильм)
10:40 Намазга өйрәник
11:05 Намазга өйрәник
11:30 Намазга өйрәник
12:00 Азан
12:05 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:25 Мультфильм (рус телендә)
12:40 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:10 Мусульмане, которыми гордится Россия
13:40 Мим
14:00 Есть хадис – есть ответ
14:20 Художественный фильм
16:00 Хикмәтле хикәяләр
16:15 Хикмәтле хикәяләр
16:30 Хикмәтле хикәяләр
16:45 Мәслихәт
17:05 Мәслихәт
17:25 Җан авазы
17:35 Җан авазы
17:45 Гаилә дәресләре
18:10 Гаилә дәресләре
18:35 Бәрәкәтле гаилә
19:20 Минбар (Җомга вәгазьләре)
19:50 Хәдис дәресләре
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Балам-багалмам
20:50 Мультфильм
21:00 Мастерская мусульманки
21:40 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:00 Мусульмане, которыми гордится Россия
22:30 Мусульмане, которыми гордится Россия
23:00 Мим
23:20 Художественный фильм

**Җәдвәлдә 10-15 минутлык үзгәрешләр булырга мөмкин.**



## «Хозур» нәшрият йорты М. Сөләйманиның дүрт томлы «Ислам тарихы» китабын нәшер итте

«Ислам тарихы» – XX йөз башында татар телендә нәшер ителгән бик кыйммәтле хезмәт булып тора. Ул гарәп кабиләләренең һәм кавемнәренең кыскача тарихын тасвирлаудан башланып, үз эченә Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел-нәсәбе, тормышы, Ислам диненең таралуы, тугрылыклы хәлифәләр чорын ала.

Хезмәтнең авторы М. Сөләймани гарәп һәм төрек телләрендә иҗат ителгән һәм дөньякүләм билгеле булган тарихи чыганакларга таяна, аларда тасвирланган вакыйгаларны чагыштырып, үз әсәрендә бары тик тикшерелгән һәм тәгаен билгеле булган мәгълүматларны туплый.

Бер гасырдан артык вакыт узгач, М. Сөләйманиның «Ислам тарихы» гарәп имлясыннан күчерелеп, янә киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

- **Кибетләрнең адреслары:**
  - Тукай урамы, 36 йорт;
  - Газовая урамы, 14 йорт.
- **Белешмәләр өчен телефон:**
  +7 (903) 388-86-33.


# КАЗАНСКИЙ ИСЛАМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ

Лицензия №1017 от 9 июня 2014 г.




**объявляет набор студентов на 2019/2020 учебный год по следующим направлениям**

| Направление | Квалификация | Форма обучения, сроки обучения | Вступительные экзамены |
|---|---|---|---|
| Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций, **профиль: Исламские науки** | бакалавр исламских наук | очная - 4 года | Русский язык, Основы ислама, Коран (знание арабского алфавита, уметь читать Коран, знать наизусть короткие суры) |
| Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций, **профиль: Коранические науки** | бакалавр коранических наук | очная - 4 года | Русский язык, Основы ислама, Коран (знание 30-го джуза наизусть) |
| Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций | бакалавр | очно-заочная (вечерняя) - 5 лет, заочная - 5 лет | Русский язык, Основы ислама, Коран (знание арабского алфавита, уметь читать Коран, знать наизусть короткие суры) |

**Необходимые документы:** копия паспорта; заявление о приеме; фотографии 3х4 - 8 шт.; документ об образовании; анкета.

Иногородним студентам предоставляется общежитие.

**ПРИЕМ ДОКУМЕНТОВ: с 20 июня по 5 августа**

**Вступительные экзамены: с 7 августа по 10 августа**

Тел. приемной комиссии: (843) 251-01-55

Электронная почта: ucheb.otdel_riu@mail.ru Официальный сайт: http://kazankiu.ru

Адрес:420049, РТ, г. Казань, ул. Газовая, д. 19


## КАЗАН ӨЧЕН АВГУСТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.08.2019 | 01:47 | 02:17 | 03:47 | 12:00 | 17:14 | 19:51 | 21:21 |
| 02.08.2019 | 01:49 | 02:19 | 03:49 | 12:00 | 17:12 | 19:49 | 21:19 |
| 03.08.2019 | 01:51 | 02:21 | 03:51 | 12:00 | 17:11 | 19:47 | 21:17 |
| 04.08.2019 | 01:53 | 02:23 | 03:53 | 12:00 | 17:10 | 19:44 | 21:14 |
| 05.08.2019 | 01:54 | 02:24 | 03:54 | 12:00 | 17:09 | 19:42 | 21:12 |
| 06.08.2019 | 01:56 | 02:26 | 03:56 | 12:00 | 17:07 | 19:40 | 21:10 |
| 07.08.2019 | 01:58 | 02:28 | 03:58 | 12:00 | 17:06 | 19:38 | 21:08 |
| 08.08.2019 | 02:00 | 02:30 | 04:00 | 12:00 | 17:05 | 19:36 | 22:06 |
| 09.08.2019 | 00:14 | 02:32 | 04:02 | 12:00 | 17:03 | 19:34 | 22:02 |
| 10.08.2019 | 00:28 | 02:34 | 04:04 | 12:00 | 17:02 | 19:32 | 21:57 |
| 11.08.2019 | 00:38 | 02:36 | 04:06 | 12:00 | 17:00 | 19:29 | 21:53 |
| 12.08.2019 | 00:47 | 02:38 | 04:08 | 12:00 | 16:59 | 19:27 | 21:48 |
| 13.08.2019 | 00:55 | 02:40 | 04:10 | 12:00 | 16:57 | 19:25 | 21:44 |
| 14.08.2019 | 01:01 | 02:42 | 04:12 | 12:00 | 16:56 | 19:23 | 21:40 |
| 15.08.2019 | 01:08 | 02:44 | 04:14 | 12:00 | 16:54 | 19:20 | 21:36 |
| 16.08.2019 | 01:13 | 02:46 | 04:16 | 12:00 | 16:53 | 19:18 | 21:32 |
| 17.08.2019 | 01:19 | 02:47 | 04:17 | 12:00 | 16:51 | 19:16 | 21:28 |
| 18.08.2019 | 01:24 | 02:49 | 04:19 | 12:00 | 16:49 | 19:13 | 21:24 |
| 19.08.2019 | 01:29 | 02:51 | 04:21 | 12:00 | 16:48 | 19:11 | 21:20 |
| 20.08.2019 | 01:34 | 02:53 | 04:23 | 12:00 | 16:46 | 19:08 | 21:16 |
| 21.08.2019 | 01:38 | 02:55 | 04:25 | 12:00 | 16:44 | 19:06 | 21:13 |
| 22.08.2019 | 01:43 | 02:57 | 04:27 | 12:00 | 16:42 | 19:04 | 21:09 |
| 23.08.2019 | 01:47 | 02:59 | 04:29 | 12:00 | 16:41 | 19:01 | 21:05 |
| 24.08.2019 | 01:51 | 03:01 | 04:31 | 12:00 | 16:39 | 18:59 | 21:01 |
| 25.08.2019 | 01:55 | 03:03 | 04:33 | 12:00 | 16:37 | 18:56 | 20:58 |
| 26.08.2019 | 01:59 | 03:05 | 04:35 | 12:00 | 16:35 | 18:54 | 20:54 |
| 27.08.2019 | 02:03 | 03:07 | 04:37 | 12:00 | 16:33 | 18:51 | 20:51 |
| 28.08.2019 | 02:06 | 03:09 | 04:39 | 12:00 | 16:32 | 18:49 | 20:47 |
| 29.08.2019 | 02:10 | 03:11 | 04:41 | 12:00 | 16:30 | 18:46 | 20:44 |
| 30.08.2019 | 02:13 | 03:13 | 04:43 | 12:00 | 16:28 | 18:44 | 20:40 |
| 31.08.2019 | 02:17 | 03:15 | 04:45 | 12:00 | 16:26 | 18:41 | 20:37 |


**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

*Июль саны, №7 (288)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Маннанова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2751
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 23 нче июлендә таратыла.
График буенча бу санга 22 нче июль көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.